



***Үзем турында үзем***

***эссе***




**«Исәнмесез», - дип башлыйм сүзем,**

**Танышулар шуннан башлана.**

**«Исәнмесез», диеп сүз башласам,**

**Бәхетем арта, күңелем шатлана.**

**Мин Бүздәк районы Каран мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Шарипова Сания Кашфулла кызы булам.**

**Максатым үземне күрсәтергә, алга - өскә таба үрмәләргә түгел, яшьләргә урын бирергә, уй-фикерләрем белән уртаклашырга. Карап утыручыларның Сәгыйт Рәмиевләр кебек үк булмаса да йокыларын ачарга; безгә, безнең балаларыбызга нинди педагоглар кирәк,**

**шуны таләп итәбез дигәнрәк фикер уятырга дигән план белән килдем.**

**Шунлыктан сүзем һәм телем белән дә җиңәм диеп уйлап, чыгышымда әллә нинди яңа ясалмалыклар алырга тырышмадым. Чөнки**

**Сөйдергән дә шул,**

**Биздергән дә шул.**

**Иң татлы да тел,.**

**Иң ачы да тел.**

**Кеше алдында мине иң гарьләндергәне — тел укытучысы буларак, чит телләр белмәвем. Дөресен генә әйткәндә, бөтен нечкәлекләре белән үз телемне беләмме икән? Узган гасырда яшәгән, тел белгече булмаган Гаяз Исхакый, Шакир Рәмиев, Ризаэтдин Фәхретдин, Дәрдемәнд кебек мәгърифәтчеләрдән ак көнләшү белән түгел, чын мәгънәсендә көнләшәм. Белемне — телне күтәреп йөрисе түгел. Корьән аятьларында Кытайга барып белем ал дигән сүрә бар. Шулай да мин заманга ияреpгә тырышам: компьютер сатып алдым, эзләнүләр юлындамын.**

**Бәләкәй чакта артист булырга хыяллана торган идем. Ходай сөзгәк сыерга мөгез бирмәгән. Кызганычка каршы, җырлый да бии дә белмим. Моңым юк минем, колагыма аю баскан. Аның каравы, аллаһы тәгалә татар хатын - кызларына хас сабырлык, түземлек биргән, моның өчен мин аңа зур рәхмәтлемен.**

**Безнең Бүздәк яклары талантларга бик бай. Районыбыз абруен мул уңышлы иген басулары, киң күңелле илгәзәк халкы белән бергә рухи байлык өләшүчеләр, шушы җирдә туып үскән бүгенге көндә зур галимнәр Мидхәт Гайнуллин, Мавлютов,Ринат Смаков күренекле язучылар Фәрит Габдрахим, Альберт Котыев, Факиһә Тугызбаева, Хәким Гыйләҗев, Гали Гатауллин, Фәния һәм Асия Чанышевалар; артистлар Рушад Мөдәрисов, Зөһрә Смакова, Хөсәен Кудашев, Зәйтүнә Насретдинова, Зәкия Арсланова, рәссамнәр Вагыйз Шәйхетдиновлар кебек талантларыбыз да күтәрә.**

**Бала чагымда мин дөньядагы барлык балалар кебек әкиятләр тыңларга ярата идем. Карт инәем бер кичтә генә сөйләп бетерә алмаган әкиятне тыңлау өчен, икенче кич җиткәнне түземсезлек белән көтеп ала идем. Билгеле, әкият тыңларга кергән күрше — күлән кич утырырга кул эше тотып керә: колак тыңлаганда, куллар йон тетә, бәйли бәйли, чигү чигә. Монда бәет әйтүчеләр дә җырчылар да була,бала-чага да кемнең нинди һөнәре бар шуны күрсәтә. Бар да игътибар үзәгендә.**

**Китаплар белән мавыга башлау, укырга кергәнче үк туган иде. «Бөтерчек» дигән әкиятне укып, күпләрне шак катырган идем. Каран мәктәбенендә укыган елларда мин китапларны су урынына эчтем. Авыл китапханәсендә дә, мәктәпнекендә дә мин укымаган китап калмады.**

**Кич утыручыларга китап сүзенең ныгырак тәэсир итүен,уйландыруын тиз сизеп алдым. Үзем укыган**

**китапның эчтәлеген сөйләгәндә, үземнең дә китап язу теләге уянды. Тизрәк үсәсе, белемле буласы килә иде. Язган әйберләрем район газетасында, балалар басмаларында дөнья күрде. Басылып чыккан нәрсәләр өчен гонарар килеп тора. Бәхеткә, беренче иҗат җимешләрем район газетасы редакторы Әнис абый Исаргаков (хәзер мәрхүм инде) кебек киң күңелле, изге теләкле кеше игътибарына лаек булды. Ул минем кулъязмаларны укып, иҗат эшенә үзенең фатихасын бирде. Беренче шигырьләремне укыганнан соң, аталарча шатланып, алтын тапкандай куанып:**

**- БДУга барасың, укырга керәсең, - дип, юллама (ходатайство) язып бирде.**

**Ә мин бәләкәйдән үк күп нәрсәләр белән кызыксына, мөмкин тиклем күбрәк белергә, күбрәк җирләрне күрергә тырыша торган идем. Үскәч тә бу теләк сүрелмәде. Шуңа үзем теләп армиягә киттем. Монда да бик күп китаплар укыдым, хыял диңгезендә йөздем.**

**Ике елдан акыл утыртып, авылга әйләнеп кайттым. Читтән торып БДУга укырга кердем. Анда Сәгыйдулла Хафизов, Камил Дәүләтшин, Суфиян Поварисов, Әхәт Нигъмәтуллин,Үзбәк Гыймадиев кебек танылган галимнәрнең лекцияләрен тыңладым, тирән белем алдым. Әкренләп белемне энҗе бөртегедәй берәмләп җыеп, тәҗрибә туплау, иҗат казанында кайнау күз алдында яңа офыклар ачты. Шунда иҗат эшендә күп язуга караганда, үз алымыңны һәм үз тавышыңны табып, әйбәт әсәр тудыру мөһимрәк икәнен аңладым.**

**Иң гаҗәпләндергәне карт инәем сөйләгән әкият-кыйссалар борынгы әдәбиятыбыз җәүһәрләре икән бит.**

**Буш вакытта кәгазь кыштырдатам,каләм тиберәтәм. Язган әйберләремне авылдашларым көтеп алалар, минем фамилия күренмәсә, юксына башлыйлар, күрәсең, ошаталардыр.**

**Сезнең игътибарга «Бүздәк яңалыкларында» газетасында басылган бер мәкаләм белән таныштырам. Ул минем турыда тулыландырыр.**

## ГОМЕР ЗАЯ ҮТМӘГӘН

**Таң алды, тышта караңгы.Аяк атлагнда, кар шыгырдаган сыман, җил дә сызгыра бугай. Торасы килмичә, җылы өйдә юрган астында уйларым белән сөйләшеп ятам. Ишек шакыйлар. Тормыйча, коры гына дәшәм:**

**- Кем анда, таң тумас борын вакытлы-вакытсыз йөри?**

**- Бу мин синең илле яшең.**

**- Илле яшь? Минем яшь булып каласым килә. Мин сине чакырмадым, ник килдең?**

**- Чакырмасалар да киләм мин шулай. Килдем, керәм. Киләсемне күптән хәбәр иттем. - Хәтерләмим.**

**- Хәтерләмисең? Менә шул склерозны да мин бүләк иттем. Чәчләреңә чал йөгерттем, күзлегең дә миннән бүләк, битеңдәге җыерчыкларны да мин сыздым...**

**- Җитте, җитте, тукта...Уз, әйдә, кунак булырсың...**

**Ул кергәч, өйне бизәдем: өстәлемә ашъяулык җәйдем, милли ризыклар куйдым, стенага сөлге элдем, паласлар җәйдем.**

**Кунагым белән ярты гасыр яшәү дәверендә ирешкән иҗади уңышларга, гайләдә һәм тормышта тоткан урыныма йомгак ясадык.**

**Тормышымда ирешкәннәрем дә аз түгел икән. Каршымда быел районыбыз хакимиятенең мәгариф идарәсе тарафыннан бирелгән ике Мактау грамотасы ята. Аларның берсе татар теле һәм әдәбияты буенча район олимпиадасына призер әзерләгән, икенчесе Башкортсанның үз ирке белән Русиягә кушылуының 450 еллыгына багышланган класс сәгате өчен бирелгән. Өч ел рәттән укучыларым белән республикада үткәрелгән иншалар конкурсында катнашып, призлы урынга лаек булып, истәлекле бүләкләрне һәм Мактау грамотасын мәгариф министрының үз кулыннан алып кайттык.**

**Мин көчле эрудицияле, үз фәннәрен яхшы белгән, эшләрен яраткан, шатлык һәм кайгыларнны чын йөрәктән уртаклаша белгән коллективта эшлим. Таң аткач, сөенә-сөенә эшкә барам, эштән соң шатлана-шатлана, өйгә ашыгам. Анда мине тормышымдагы ныклы таянычым Тәлгатем көтә. Бергәләп тәриялəп үстергән улларыбыз Марс һәм Венер тормышта үз урыннарын таптылар, абруйлы урыннарда эшлиләр. Быел оныкабыз Даниэлла якты дөньяга аваз салды, тәпи китәргә җыена. Бәхетнең олысы - шулдыр. Бәхетемне түп-түгәрәк, дия алмасам да (кызыбыз Алия**

**күзләрен мәңгегә йомды), Биш дистә еллык гомерем үреннән артка борылып карап, шуны ныклы әйтә алам: гомерем зая үтмәгән...**

**Шулай тәмамладык без гәпләшүне.**

**Без эшебезне яшь көйгә башладык. Безнең чор кешеләре унынчы класстан соң, укырга керә алмаганнар райкомнарга инструктор, кибетләргә сатучы, басуларга тракторист, фермаларга савымчы булып эшкә киттеләр. Мин дә шулар исәбен тулыландырып, мәктәпкә укытырга килдем. Тормыш куйган киртәләрне яшьлегебез белән җимердек. Бүген кулында ике дипломы булган яшьләрдә дә бер тамагын туйдырырлык эш юк. Моңа мин бик борчылып матбугат битләрендә чыгыш ясадым. Быелгы 2009 нчы ел Башкортстан Республикасы Президенты Указы белән Яшьләр башлангычларын яклау һәм үстерү елы дип игълан ителүен хуплыйм. Президентыбыз Мортаза Гобәйдулла улы Рәхимов, күрүебезчә, бүген дә күп кенә егетләргә биргесез көчле инергияле зур тормыш мәктәбе үткән тәҗрибәле җитәкче.**

**Мәктәп - изге урын. Элек тә шулай булган Хәзер дә... Туган төбәгенең, авылының, районының киләчәге турында уйлый белгән кеше, һичшиксез мәктәпкә, балалар бакчасына бик игътибарлы булырга, алар хакында ихлас күңелдән кайгыртырга тиеш. Киләчәк буын шунда тәрбияләнә. Нинди буын үсәр? Без кем кулына калырбыз? Безнең хакта кем кайгыртыр? Шул хакта онытырга ярамый. Укытучылар район интеллигенциясенең иң көчле һәм иң күп санлы**

**вәкилләре. Халык арасында аларның сүзе бик үтемле. Балалар аркылы да алар ата-аналарга зур йогынты ясый, үз фикерләрен үткәрә алалар. Педагоглар шәхес тәрбияләүдә зур роль уйныйлар, милләтпәрвәрләрне үстерүдә аларга зур вазифалар йөкләнә. Укытучыны мин күркәм сыйфатлар иясе, үз эшенә бирелгән шәхес дип күзаллыйм. Тик шунсы кызганыч, безнең арада көчле затлар чәкчәк бизәгедәй бик әз. Моның шулай булуы бигрәк тә патриотик тәрбияне аксата. Әлбәттә, һәр кеше үзенең киләчәген мәктәп белән бәйләгәндә нинди катлаулы һәм четерекле юлга басуны аңлап атлый, баланы кеше итүдә үз өлешен күреп сөенүче дә ул. Укытучы галим дә, гадел дә, күркәм дә, сабыр да, гүзәл дә. Күпләр өчен ул- идеал, үрнәк кеше дә.**

**Мин ышанам: минем укучыларым тормышта үз урыннарын табарлар, туып-үскән җирнең кадерен белерләр һәм Туган илебезгә, халкыбызга изге эшләр генә эшләрләр.**

**Галәм кояшы белән якты, ә кеше белеме белән күркәм, көчле була. Юлларыгызда белемгә сусаган, иксез-чиксез белем дәрьясын кичеп чыгарга әзер торган укучылар очрасын, сезне шатландысын иде.**

# Туган телем – изге гөлем.

**Минем туган телем  татар теле. Бу телдә “әннәм” дип, “мәммәм” дип минем телем ачылган. Бу телгә мәхәббәт телем ачылганчы ук җырлаган бишек җырыннан, карт инәем сөйләгән әкиятләрдән күчкән. Хәреф танырга өйрәнгәч, рәсемле китаплар укырга ярата идем. Әле дә хәтерлим, 1 нче сыйныфка укырга барганчы ук, “Бөтерчек” дигән әкият китабын укып чыктым. Урта һәм югары сыйныфларда укыганда, мин ныклап торып китап уку чире белән чирли башладым. Бүген бу “авыру”ны һични белән дә дәвалап, берни белән дә алмаштырып булмый. Матур әдәбият әсәрләренең нинди телдә язылуы минем өчен мөһим түгел, ә күңелгә үтеп керерлек булсын. Мин Башкортстанда һәм Татарстанда чыккан “Агыйдел”, “Идел”, “Тулпар”, “Казан утлары”нда басылган материаллар белән танышып барам.**

**“Башкортостан укытусыһы”, “Мәгариф” журналларында, “Ачык дәрес”, “Тәрбия” газеталарында басылган методиканы өйрәнәм.**

**Мәгърифәтче язучыларның югары белем алмасалар да күп тел белүләренә көнләшеп карыйм. Алар янында үземне күзле сукыр итеп тоям. Күп тел белү – нинди бәхет. Белемне күтәреп йөрисе түгел. Гыйлем алырга Кытайга кадәр барганнар. Безнең буын 10 нчы сыйныфтан соң ук укыта башлады. Без яшьлек белән көчле идек. Шуңа мин КМО җитәкчелеге кебек**

**эшләрне, түгәрәкләрне, дәресләрне яшьләргә бирү ягында. Тәҗрибә ул эшли – эшли туплана. Мин булдыралам дип, барсын да үзебезгә алу ягында түгел. Яшьләр өйрәнсеннәр, без алар сораганда, киңәшебезне генә кызганмыйк. Минем дәресләрне, түгәрәкне яшь укытучыга, (үземнең укучыга) Таңсылу Хәкимовага бирделәр. Аның матур гына эшләп йөрүе – минем өчен шатлык. Аның каравы дәүләт теле буларак башкорт телен тәкъдим иттеләр. Мин бик теләп бу эшкә алындым, үземне икенче сулышым ачылган сыман тойдым. Бу туган телгә хыянәт итәм дигән сүз түгел, ә тагы бер тел беләм дигән сүз. Үзең генә белү әле ул әллә ни түгел. Ә менә кемнедер үзең белгәнгә өйрәтү – бу инде нәрсәдер. Моның өчен үзең методика уйлыйсың, бу фәнне яраттыра белү алымнарын эзлисең. Эзләнгән саен үзеңнең белмәгәнлекне ныграк тоясың һәм үзеңә генә хас педагогик алымнар тудырасың. Хезмәттәшем Гәлләмова Ф.А. белән һәрчак тәҗрибәләребезне уртаклашабыз, киләчәккә планнар корабыз, үз эшебезне ачарга җыенабыз. Эшеңнең нәтиҗәсен күрсәң – канатлар үсә.**

**Укытучы йортлар салмый, машиналар ясамый – бер караганда эшнең сөземтәсе дә сизелми. Икенче караганда, укучыларның иншалары республика күләмендә урын алса, олимпиадаларда катнашса, син укыган факультетны сайласа, алар арасыннан танылган журналистлар, язучылар чыкса – хезмәтең бушка узмаган дигән сүз. Димәк куйган максатың, күрсәткән юлың дөрес. Артка борылып карарга да ирешкәнең белән канәгатьләнеп, яшьләргә юл**

**күрсәтергә, ярдәм кулы сузарга кирәк. Тормышта үз юлың булу, үз урыныңны үзең белү – кешеләргә кирәк икәнлегеңне күрсәтеп тора. Әгәр син кемгәдер кирәксең икән – бу яшәү көчен арттыра. Минем карт инәм биш вакыт намазын һәм уразасын калдырмады. Аның бу күркәм гадәте әниемә дә күчте. Мин әниемнән иман нуры алып яшим. Киләчәктә үзем аның кебек кеше булырга җыенам. Ә этиемнең энисе әлифне таяк дип тә белмәде, әмма борынгы әдәбияттан ул белмәгән кыйсса бар идеме икән? Мин шуларны тыңлап, шулардан фәһем алып үстем. Ике картинәмнән дә үрнәк алып, оныкларымны туган телләрен, туган нигезләрен, нәселләрен яхшы белә торган балалар итеп тәрбияләрмен һәм үземнең урыным аларның түр башында булыр дип уйлыйм.**

**Илне тоткан телем,җирем бар**

**Төрмәләргә дә яптылар**

**Җәлил белән бергә сине**

**Ассалар да, киссәләр дә,**

**Үлмәдең син, калдың тере.**

**Ш. Маннур.**

**Газиз туган телем! Җир йөзендә яшәгән һәрбер кеше өчен үзенең туган теле икмәк кебек кадерле,газиз, назлы да. Җыр кебек моңлы да ул! Татар теле! Һәр милләт кешесе өчен иң моңлы ул көй – үзенең милли көе, иң матур, иң кадәрле тел – үзенең туган тел. Минем өчен татар теле - әнә шундый. Ул күп гасырлар буе үсеп шомарып килгән һәм шактый камилләшкән.**

**Татар теле... Күп гасырлык тарихы булган, Каюм Насыйрилар, Тукайлар нигез салган, 7 миллион халык сөйләшкән, дөньядагы иң дәрәҗәле 14 тел исәбенә кергән чит илләрдә дә өйрәнелә. Моабитның таш диварлары эчендә дә тынмыйча, аның калын стеналарын тишеп чыгып, бөтен дөньяга яңгыраган, утларга – суларга салсалар да, ассалар – киссәләр дә исән калган, иң – иң авыр кимсетүләргә дә түзгән, сынмаган – сыгылмаган, баш имәгән горур татар теле!**

**Туган тел төшенчәсенә зур мәгънә салынган. Ул Ватан, туган җир, ата – ана сүзләре белән бер үк дәрәҗәдә торучы бөек, изге һәм кадерле сүз. Ул телне шуңа күрә туган тел дип атыйлар да.**

**Ул телгә баланы аның иң газиз, иң якын кешесе анасы өйрәтә: шул телдә аңа бишек жырларын җырлый, иркәли, юата. Шуңа күрә аны халык ана теле дип атый. Ана теленең бөтен гүзәллеген аңлаганда,аның иң матур үзенчәлекләрен белгәндә һәм сөйләшкәндә генә без заманыбызның югары мәдәниятле кешеләр була алабыз.Шушы зур бәхетне югалтмас өчен без үзебезнең телне белергә,яратырга һәм сакларга тиешбез.Ана теле ягымлылыгы белән күңелне юата,тәэсирлеге белән изгелек хисләре уята.Ягымлы ана теле,бигрәк тә бала өчен аң-белем һәм тәрбия бирүче иң шифалы чишмә-чыганак.Халык үзенең телен,оста бакчачы кебек,яман җилләрдән,рәхимсез салкыннар куырудан саклап,мең еллар буена үстереп килгән,аны өзлексез баетып,матурлап,иң тирән фикерләрен,иң нечкә хисләрен дә аңлатып бирер дәрәҗәгә җиткергән.**

**Башкортстан-туган җир.Биредә мин татар мәктәбендә укыйм.Укытучыларыбыз безгә дәресләрдә туган телебезнең серләрен белергә,әдәбиятыбызны,халкыбызны сөяргә өйрәтә. Без татар теле һәм әдәбияты буенча үткән чараларда,кичәләрдә актив катнашабыз.Аяз Гыйләҗевның юбилее булды.Шул бәйрәмгә багышлап укучылар бик матур кичә үткәрделәр. Аның “Яра” әсәре буенча китап укучылар конференциясе булды.**

**Татар теле-татар халкының үзара аралашу коралы гына түгел,ул-безнең ата-бабаларыбыздан калган мирас та.Туган телебез моңлы да,күәтле дә,көчле дә,бай да.Без аның ярдәмендә халкыбызның иҗатын,тарихын өйрәнәбез.Туган телебезнең тирән мәгънәле сүзләре,гыйбарәләре,бай мәкаль-әйтемнәре белән без татар теле дәресендә танышабыз.**

**Икенче сүзләр белән әйткәндә,туган телем-фикерләү сәләтен формалаштыручы,тәрбия бирүче,хис-тойгыларны белдерүче,туган илне,халыкның рухи дөньясын баетучы көч.**

**Безнең туган телебездә-халкыбызның рухи байлыгы,ул гасырлар агышында үскән,камилләшкән,бу мирасны сакларга бурычлыбыз. Без шуңа да телебез сафлыгы,матурлыгы,аһәңлелеге өчен барыбызга да армый-талмый көрәшергә,эшләргә кирәк.**

**Төрки телләр арасында башкорт һәм татар телләре бер-берсенә иң якын телләр.Бу якынлык борынгы чордагы бердәмлек белән генә түгел,соңрак чорда-**

**мөстәкыйль төрки телләр формалашу процессы кичергән чорда барган үзара мөнәсәбәтләр белән аңлатыла.**

**Татарлар бик күп халыклар белән аралашып яшәгәннәр.Аларның бәйләнешләре хәзер дә дәвам итә .Башкортлар һәм татарлар исә тарихи,рухи,мәдәни һәм тел ягыннан иң якыннар,туганнар.**

**Зур тормышка аяк басканда, дөньяны киңрәк таныганда,изге хисләр башкарганда, туган телебез, ышанычлы юлдаш, ярдәмче булып,безгә**

**көч ,илһам,дәрт биреп тора.Соңгы вакытта кешеләрдә туган теленә кызыксыну арта.**

**Алар туган телләрен саклауның ничек әһәмиятле булуын аңлый.Үз телен,башка телләрне белеүе кешенең мәдәниятлеген күрсәтә.**

**Туган илемдә туган телемдә сөйләшә алганга мин бәхетле.**

**Тел язмышы-халык язмышы бит ул.Шушы хакыйкатьне һич тә истән чыгармаска иде.**

**Соңгы елларда шәһәрләрдә дә татар теленә игътибар артты,татар гимназияләре ачылды.Шәһәр балаларына да үз туган телендә белем алырга мөмкинлекләр туды.Минемчә,без бәхетле буын балалары.Үзебезнең туган телебез-татар телендә белем алабыз.Без туган телебезне ничек яратсак,ул шундый дәрәҗәдә сакланыр,үсәр һәм ныгыр.**



**Кисек тел**

**(парча)**

**Башлыйк әле сүзне Каран илә**

**Мәктәбебезгә елына кәм дигәгәндә өч директор киләә.**

**Каяндыр акча таба: өй сала машинада җилә**

**Укытучы бахыр тузган киемеңне илә дә илә.**

**Бу Каранда биналар күп аллы- артлы корыла торыр.**

**Мәктәп белән чагыштыргaнда, калганнары чүп торыр.**

**Мәктәп дигәне бер юктан башыңа орыр,**

**Моның  өчен мецләгән ятьмә корыр.**

**Хак тәгалә нәрсә кылса ирке бар:**

**Тәрбиялиләр уйнаштан бала тапканнар,**

**Кендекләрен күрсәтеп киеп чалбар,**

**Мода куам диеп куян артыннан чапканнар.**

**Телләр өйрәтә торган укытучылар бар.**

**Белемнәре юк, укытырга ярый дигән**

**Повышениедән алып кайткан кәҗә билетлары бар.**

**Алардан текәрәк кеше юк, мәктәп каридоры тар,**

**Зато минем юбилей дип елап алган грамоталары бар.**

**Бер хикәят килде телемгә арый,**

**Яхшылап сөйләп биреп булса ярый.**

**Бәян итәргә Шәрипова тырыштырып карый,**

**Белеп тора: моның өчен добрый гына баләләргә тарый.**

**Таңга калсын бала-чага  , ата-ана**

**Укучылар, укытучылар итсен тантана.**

**Шуңардан абруй гына арта аңа.**

**Бер заман бардым мәктәп базарына ,**

**Шунда таптым азык язарыма,**

**Очлы казык башыма казарыма.**

**Иртән иртүк кайнамакта бу базар:**

**Кычкырышалар , шаулашалар кем узар.**

**Карап карасыннар мине дә узып кем кызар.**

**“Көфер почмагы”ннан монда һич ким түгел:**

**Иртә таңнан берәүләр гайбәт сата,**

**Поты тишекле бер тиен: кемнең сыеры бозаулаган,**

**Кем артына кояш төшкәнче йоклап ята.**

**Укытучылар AVON , AMWOYише нәрсә саталар**

**Алмасаң, ”2”чәпәп, мылтыксыз аталар.**

**Шак катып тамаша итә ишек төбендәге каталар.**

**Икече берәүләр күчерә, сыза , боза, яза ,**

**Шыгыр –шыгыр кәгазь кыштырдата,**

**Үзләренчә олы эш кыйрата.**

**Башлар каткан таш кебек, БДИ котны ала,**

**Йомры башлар да шомланып телсез кала.**

**Ел буе югарыдан тикшерү көтеп күз тала.**

**Фәннәр әллә ни эшләгән , буталган.**

**Дәрес бирүчеләрне түрәдән курку уты алган.**

**Башлар телсез, телләр башсыз торып калган.**

**Тарихчы Илшат физик булып алган.**

**Биолог география укытып йөри,**

**Физкультурник завучлыкны сөйри,**

**Химикка Башкортостан культурасы ,**

**Татар теле урынына башкорт теле йөри.**

**Сания, Флүрә, Зөһрәләр**

**Сүнгән телгә үзләренчә җан өрәләр,**

**Килгән түрәләргә берчә ялагайланалар,**

**Берчә ник алай, безнең тел кая дип өрәләр.**

**Без яшәсәк –тел югалмас һич!—диләр.**

**Ата- аналарга синең телең бар ни , юк ни-бер тиен.**

**Татар ни, башкорт ни барыбер ич диләр,**

**Балалары көйли эти-әни көен.**

**Телчеләрнең шау-шу килгән базары бу.**

**Укучыларның телгә битарафлык базары бу.**

**Түрәләрнең сүз юктан сүз булсын дип азары бу.**

**Әтәчегез күкәй салган , чыгып карагыз абзары бу.**

**Телчеләрнең кай якка булырга белмәгән аһ-зары бу.**

**Һәр заманда монда хәлләр шул икән,**

**Һәркем үз эше белән мәшгуль икән.**

**Шул вакыт чыкты давыл, купты тавыш.**

**Китте “Көфер почмагы”на таба чабыш.**

**Онытылды бар эшләр, килгән табыш.**

**“Почмак” та бүген бер якка авыш.**

**Бар да гаҗәпләнә:нәрсә бар?**

**Әллә җәй уртасында яуганмы кар?**

**Укучылар арасында туганмы яңа пар?**

**Бер сугыш чыкканмы , я пожар?**

**Барсының күзе маңгайда: тәгәрәп бер баш килә,**

**Язучылар каләменә майлы аш килә.**

**Башка күз салсам, ишетәм тирә-яктагылар такмаклый илә:**

**-Татар буласың килсә, Татарстанга кит ,-диләр,**

**Юк икән, башкорт телен үз ит диләр.**

**Йөз меңлек премияләр алырлык татарча укыттың,**

**Дальше-больше башкортчага аптимизироваться ит,-диләр**

**Эшли алмыйсыңмыни, мокыт,- диләр**

**Укытучымын дип йөрисең маңкорт,-диләр.**

**Кәмит карауч ыларның юк саны.**

**Телем кисек, яклаучысы юк аны.**

**(Аллага шөкер,кулымнан килмәгән эш юк**

**Укытам: сарык та исән, бүре дә тук.)**

**Кисек тел сөйли, аның сөяге юк:**

**-Минем данлы чакларым бар иде.**

**Туган илем – данлыклы Болгар иде.**

**Чит итеп карады миңа  һәр дуңгыз:**

**Яу белән килде миңа  явыз Чыңгыз.**

**Туган телемне кол итте, илемне көл итте,**

**Килеп яра өстенә яра өстәде Иван Явыз**

**Сүзләремне бастырды чикләү белән,**

**Сафлыгымны таптатты чиркәү белән.**

**Күтәрәләр тел мәсьәләсен депутатлар.**

**Аңламыйм: татар телен укытабыз дусларча,**

**Журналга темаларны язабыз рус телендә русларча.**

**Башкорт телен укытыр өчен, башкорт булып туу кирәк.**

**Министрларны уйландыру өчен, бердәм милләт булып,**

**Таләпләрне дөрес кую кирәк.**

**Аңламыйлар икән эшләреннән куу кирәк.**

**Башкортстан милләтләр гөлләмәсе - белү кирәк,**

**Һәр милләтнең үз телендә уку булсын.**

**Республика милләт сөйләшеннән гөрләп торсын.**

**Фагыйлатын, фагыйлатын, фагыйлат,**

**Телчеләрнең барсының күңеле шат.**

**Милли женнең ни азса да күрке бар;**

**Сания Шәрипнең ни язса да ирке бар.**

*************************************

**Авылдашларым сезнең өчен.**

**===============**

**Ашыга-кабалана барганда,**

**Иртән яраткан эшемә**

**Сәлам бирәм күршеләргә**

**Исәнлек юллыйм кешегә:**

**-Уңыш насыйп итсен Ходай**

**Һәммәгезгә, безнең ишегә.**

**Хәерле эш сәгате теләп,**

**Ихлас күңелдән елмаеп,**

**Озатып кала урамдашлар.**

**Иңнәремә канат үсә.**

**-Рәхмәт сезгә, авылдашлар.**

**Шатлыктан күңелем тула,**

**Илһам уяна, яңа җыр туа:**

**-Уңышларым, хезмәтем,көчем**

**Авылдашларым, сезнең өчен.**

**Сөенеп эшемнән кайтам,**

**Җырны җырлый-җырлый кичен**

**-Сезне чын йөрәктән яратам.**

**Уңышларым, хезмәтем,көчем**

**Авылдашларым, сезнең өчен.**

******************

# *ТЫШТА КЫШ.*

============

*Тунан ягыма килеп җитте*

*Көтеп алган ак тунлы кыш та*

*Җилләр уйный, карлар котыра,*

*Бураннар елый, улый тышта.*

*Гел чыгасы килеп тора*

*Суыкка уйнарга урамга.*

*Көртен җимереп, карын ватабыз,*

*Тагы эш ясыйбыз буранга.*

*Безне чынлап куркыткан була,*

*Колак очларын чеметә,*

*Тирләп-пешеп уйный башласак,*

*Юашлана,усаллыгын киметә.*

*Шуны гына көткән дуслар*

*Чана сөйрәп, чаңгы тагып,*

*Тау башына менеп китә.*

*Җил куып, тау шуып,*

*Вакыт үзенекен итә.*

*Сиздермичә көн, кыш үтә.*

***Бары бер мизгел***

***Син үзеңә гашыйк иттең,***

***Гүя бирдең очарт канат.***

***Оча-оча кабатлыйм,***

***Ярат мине, берүк ярат.***

***Яратсаң, канатларым***

***Җилдә кайрылмый.***

***Булмыйк ай белән кояштай,***

***Бергә яшик айрылмый.***

***Яраткач, куркыныч түгел,***

***Нигә шунда җир ярылмый.***

***Син булгач, эш-укулар***

***Таудай булсын, һич арылмый.***

***Бу мизгелне сагына бел,***

***Сагынуларга табына бел,***

***Хыялың канатларын***

***Сабыр гына кагына бел.***

***Уйла шул хакта гына гел:***

***Онытма тормыш, гомер,***

***Яшәү – барысы – бер мизгел,***

***Бер күз ачып йомган ара.***

# *БАШКОРТСТАН ТАТАРЛАРЫ.*

***Башкортстан татарлары***

***Кадерли милли телен.***

***Канын кояр, утка керер***

***Тынычлыгын саклап иленең.***

***Берлинны яулаган,***

***Җиңү Байрагы кадаган,***

***Һич кайчан югалып калмаган***

***Башкортстан татарлары.***

***Башкортстан татарлары –***

***Республикабыз чәчәге без.***

***Яшибез бердәм, дус булып.***

***Ышанычлы киләчәгебез.***

***Халкым иген үстерә,***

***Дәүләт бурасын тутырып,***

***Нефть таба, алтын чыгара,***

***Кул кушырып тормый утырып.***

*Башкортстан татарлары*

*Башкорт белән бертуган.*

*Малы уртак, җире уртак.*

*Алар гомер тату булган.*

*Ирек даулап бергә көрәшкән.*

*Дуслыкка таулар көнләшкән.*

*Горурлык хас аларга,*

*Сабырлык хас аларга.*

*Телим сәлам барларга*

*Илемнең кыз- улларына.*

*Хөрмәтләп баш иям халкыма,*

*Республикам татарларына.*

*****************

**Башкорстаным бәйрәм итә**

**Башкортстаным бәйрәм итә,**

**Юбилей көне бүген.**

**Туган көнгә килгән кояш,**

**Нурга манчып күген.**

**Башкортстаным бәйрәм итә:**

**Җырлый, бии, уйный-көлә,**

**Шатланып курай тарталар.**

**Төрле милләт вәкилләре**

**Бар да илемне яраталар**

**Төрле милләт кешеләре**

**Дуслык букеты хасил итә.**

**Шул гөлләмәгә сокланып**

**Иркәләргә туа һәр иртә.**

**Милләт дуслыгы – ил бизәге**

**Өр яңа үрләргә илтә.**

**Җиребез шат, илебез тыныч.**

**Республикам бәйрәм итә.**

**=============**

***Бәйрәмең белән, гәзитем!!!***

**Башкортостан Республикасы**

**Матбугатының атказанган хезмәткәре**

**Туктамышев Данил Хәлим улы**

**Районкабызны җитәкли.**

**Шуңа тиражы күп, даны олы.**

**Шулай түгел что ли, ни тәк ли?**

**Реклама бүлегендә**

**Фоат кызы Рәмилә**

**Ярдәм итә, киңәш бирә**

**Шуңа күпләр аңа килә.**

**Өч телне дә яратып,**

**Хатасыз текстлар җыя**

**Барый кызы Зөлфия,**

**Шуңа ул абруйга ия.**

**Районкада ничә еллар,**

**Шофер Яркәев Зирәк.**

**Андый оптимистлар кирәк,**

**Яхшы кешелек, эшлеклек**

**Сифатлары бүген сирәк.**

**Тәрҗемә бүлеге остазлары:**

**Резида, Тәслимә, Рәсимәләр!**

**Сүз сулышын, мәгънәсен тоемлап,**

**Су урынына имәләр.**

**Шуңа районкага тирә яктан,**

**Хәбәрләр чутсыз киләләр.**

**Альфреднең эше дә авырдан,**

**Ул җыя хәбәрләрне авылдан.**

**Мәгълүматны таба Светлана,**

**Яңалыкларына күңел шатлана.**

**Хатларга Ирина җаваплы,**

**Башкарган һәр эше саваплы.**

**Алар ярган сукмактан атлый**

**Лилия һәм Люцияләр.**

**Үз бурычларын  үтәп , эшне,**

**Илне, халкыбызны сөялә**

**Шуңа  бар да : “Үзебезнең**

**Бүздәк районкасы,” –дияләр,**

**Башкаларга сиздерми генә**

**Мактаналар, күкрәк чөяләр.**

**Верстка буенча инженерлар**

**Минзәрә белән Алия**

**Үзләренә генә хас-**

**Серле талантка ия.**

**Шуңа да бит инде районка-**

**Вакытында “кием кия”,**

**Укучыларга атлап түгел,**

**Йөгереп чабып килә.**

**Фотога кагылышлы эшне**

**Башкара тәвәккәл Дания,**

**Компьютерны авызлыклады,**

**Бу “батырлыгы” данга ия.**

**Көн дә кабатлана  таныш эш:**

**Тәмли-тәмли җим чүпләгәндәй**

**Яңа чыккан сары чебеш,**

**Чибәркәй Шамил кызы Зилә**

**Иҗекләп хаталар чүпли.**

**Хезмәте кулыннан килә,**

**Шуңа гәзит хаталы үтми.**

**“Штаб начальнигы” Фирдәвес**

**Редакциянең җаваплы сәркатибе**

**Ачык йөзле, ихлас күңелле**

**Тәҗрибәлелектә юк аңа тиңе.**

**Татар телендәге гәзиткә**

**Җан  өрүче фәрештәләр:**

**Заһира белән Сания,**

**Баш  күтәрми гел эштәләр.**

**Районка яшәде, яши ,яшәр.**

**Редакциянең бугалтеры Флүрә**

**Сиксән яшьлек ак сакалның**

**Киләчәген алдан күрә.**

**Бүлмәләрдә тазалык,**

**Йөзендә кояш елмаюы**

**Рәфидә тудырган мөхит.**

**Дәртләнеп, йөзеп эшлә,**

**Илһамланып иҗат ит.**

**Бәйрәмең белән, гәзитем,**

**Җан  кисәгем, бавыр итем,**

**Сине байтактан үз иттем.**

**ТУГАН  КӨНЕҢ  БЕЛӘН  ГӘЗИТЕМ!!!**

**---------------------------**

## БҮЗДӘК   КИЛЕННӘРЕ.

**Чиядәй иренәреме?**

**Өзелеп торган билләреме?**

**Утка сала ирләрне.**

**Килен булып киләләр,**

**Калдырып үскән җирләрне,**

**Безнең Бүздәк киленнәре!**



**Бүздәк егетләре сайлый**

**Кызларның иң асылларын:**

**Эш рәте белгәннәрен,**

**Бүздәккә күңел биргәннәрен,**

**Килене булам дигәннәрен,**

**Олысын, кечесен зурлап,**

**Хөрмәтләп баш игәннәрен.**

**Әллә каян танып була**

**Безне – Бүздәк киленнәрен.**

**Төшкән урынына таш була**

**Безнең Бүздәк киленнәре.**

**Гаиләсенә баш була**

**Безнең Бүздәк киленнәре.**

**Итәк тутырып бәби таба,**

**Үстерә, тәрбияли, бага.**

**Күп балалы ана медален**

**Горурланып түшенә тага**

**Безнең Бүздәк киленнәре.**



**Сыерлар көтүдән кайта,**

**Җиргә тия җиленнәре.**

**Шулардан чиләк тутырып,**

**Күбекләндереп сөт сава**

**Безнең Бүздәк киленнәре.**

**Яңа сауган сөт кебек**

**Ап-ак, изге күңелле,**

**Яңа туган бала кебек**

**Эчкерсез пакъ йөрәкле.**

**Һәркемгә һәрчак кирәкле**

**Безнең Бүздәк киленнәре.**

**Йорт төзетә,өй туйлата,**

**Чүпне зур акча итә,**

**Кулында ут уйната**

**Безнең Бүздәк киленнәре.**

**Безнең Бүздәк киленнәренең**

**Адымы ышанычлы, белә**

**Баскан җирен гөл итәчәген.**

**Үзенең булдыклыгында**

**Күрә бәхетле киләчәген.**

# ӘНИЕМӘ.

**Кадерле әнием, син,**
**Булганда кырымда,**
**Кулларың сыйпавы -**
**Дәва да, ырым да.**

**Үзеннән үзе җыр туа,**
**Әнием турында.**
**Рәхмәтем зур сиңа,**
**Шуны данлыйм җырымда.**

**Әнием, йөрәгең-**
**Һәркем шифа табарлык.**
**Курыкма картлыктан,**
**Телим сиңа сабырлык.**

**Әнием – илем гүзәле,**
**Гомеренең көз мәле.**
**Ялгызлык –сырхауларга,**
**Бирешмә, түз әле.**

**Әнием – сыңар канатым,**

**Саксыз кыйланып уйламый.**

**Күңеленңне канаттым,**

**Син һаман мине яраттың.**

**Әнием кадерлем,**

**Хөрмәтлем минем, зурым.**

**Изгелекләр юлыйм,**

**Бердәнберем, күз нурым.**



# КӘРИМ – БАШКОРТСТАН ГАГАРИНЫ

**Вәлиди – Башкортстан терәге,**

**Туган ил дип янды йөрәге.**

**Бүздәктән Муллаян Халиков**

**Булса илебездә иң кирәге.**

**Халиков – башкорт самородогы,**

**Тамъян-Катай кантон ревкомы рәисе,**

**Социаль тәэминат наркомы,**

**БАССР мәгариф наркомы.**

**Бишбүләкнең егет кешесе**

**Кәрим Хәкимов алдында**

**Киңәш тотты олысы – кечесе.**

**Күп булды кырында илчесе,**

**Гарәп халкының баш игәне,**

**Үзебезнең Кызыл Паша дигәне.**

**Нахакка җәзаланып, гаепләнеп,**

**Ишкәкләрне бергә ишкән иде.**

**Хөкүмәт ит турагычыннан үтеп,**

**Йөрәкләрен пуля тишкән иде.**

**Алар онытылып та беткән иде.**

**Аларның яшәү девизы –**

**Дуслык булсын сокландырылык,**

**Татулык –мәңгелек, гомерлек**

**Дошманнарны көнләштерерлек.**

**Хакыйкать кире кайта икән.**

**Капчыкны тишә алмыйча,**

**Без кырык ел ята икән.**

**Дөреслек барыбер калка икән.**

**Җиһанны әйләнде Гагарин.**

**Кәрим Башкортстан – Гагарины.**

**Согуд Гарәстанын иңли аңы.**

**Фарсы иле, Хиҗаз корольлеге**

**Космонавтка тиңли аны.**

**Хәкимов соңгы сулышына кадәр**

**Үз иленә тугры булып кала,**

**Киләчәккә өмет белән яна,**

**Көчле ихтыярлы булганга,**

**Генераль консул исеме ала,**

**Халык арасында абруй казана.**

**Барлык көчен акылын туплап,**

**Кәрим Гарәпстанга салган сукмак**

**Ышанычлы өметле иде,**

**Буржуйларга  булды каты тукмак.**

**Кызлар пәрәнҗәләрен салды,**

**Безнең сыман чалбар киеп алды.**

**Укыйлар, эшлиләр, төзиләр,**

**Без бәхетле диеп йөриләр.**

**Көннән –көн ныгый илләр арасында**

**Милләтләр дуслыгының күпере.**

**Моны күреп сөенә җаны**

**Хәкимовның, гүя ул тере.**

**Аны Нәҗип агай терелтте,**

**Сүрия сәхнәсенә мендерде.**

**Кәрим Хәкимовның исемен**

**Бөтен дөньяга белдерде.**

**Кызыл пашаны башкарып,**

**Әхтәм Абушахманов уңды,**

**С.Юлаев исемендәге**

**Премия лауреаты булды.**

**Вәлиди Туган, Халиков,**

**Хакимовлар турында**

**Киләчәктә туар җырлар.**

**Курайга кушылып яшьләр**

**Гимн урынына җырлар.**

# ПЕСИЯГӘ КИТМӘГӘН ПЕНСИЯНЕРЛӘРГӘ

*Яшең җиттеме,*

*Вакытында китә бел.*

*Яшьләргә юл бир:*

*Кит хаклы ялга,*

*Кадыр эшеңне, бул ир.*

*Эшләгәнеңне күрде мир.*

*Башкаларга да кирәк*

*Синябышып яткан җир.*

*Мин, мин дип йөрү ,*

*Акча артыннан куу –*

*Үзе яман чир.*

*Байлык, мал дип күпме*

*Түктең ләбаса тир.*

*Син – дөнья тоткасы,*

*Син генә күп белгән.*

*Син белгәнне инде*

*Яшьләр киптереп элгән.*

*Бул гаиләң учагы.*

*Акча тапмасаң да*

*Ачык йөзләре,кочагы.*

*Бел синең алар өчен*

*Кадерле, кирәк чагың.*

=============

## КАРТАЯ АВЫЛ

**Картая авыл,**

**Кычкыр каравыл.**

**Яшьләрне йоткан**

**Кала һәм давыл.**

**Карая авыл.**

**Урамда һич күренми**

**Кеше, олысы-яше.**

**Буш урамны кызганып,**

**Ага күзнең яше.**

**Авыл картая.**

**Адәм баласы туа,**

**Үсә, читкә тая.**

**Авыл картая.**

**Иркен урамда юк**

**Тавыш-тын, бала-чага.**

**Ярый, табигать җанлы:**

**Күктә болыт ага;**

**Әнә күчмә кошлар**

**Җылы якка юл алган,**

**Китәргә канат кага:**

**Җиңел кауры йлары**

**Артларыннан җиргә**

**Коела, оча, тама.**

**Алардан калышмый**

**Йөгерек еллар чаба**

**Сабыр картлыкка таба**

**Картаябыз без,**

**Картаясыз сез**

**Кычкыр каравыл,**

**Картая авыл.**



# БҮГЕНГЕ КӨН ГЕРОЕ

**Завод- фабрикалар салмый,**

**Янгыннар сүндерми,**

**Фашистлар да атмый,**

**Аунап яткан чүптән дә**

**Алтын, акча ясый,**

**Заманнан алда чаба,**

**Тормышны йөгәнли,**

**Нигә тотынса да,ут яна,**

**Булдыклыгына күз иярми,**

**Язмышның үзен иярли –**

**Шуңа зур абруе**

**Ул бүгенге көн герое.**



**Итәген кисеп, җиңен ямый.**

**Кредит алып , суда түли.**

**Иген үстерә, мал үрчетә.**

**Малын сатып,иген ала.**

**Малын саткач, үзенә ашарга**

**Эч- карынлык кына торып кала.**

**Ал-ял белми,көн-төн дими,**

**Җигелеп эшли дә эшли:**

**Борынын алса, томшыгы…**

**Томшыгын алса, борыны…**

**Бу да бүгенге көн герое.**

**Читтән караганда ул иң бае.**

**Кояш чыккан, аңа рәхәт.**

**Яңгыр яуган – үзе бәхет,**

**Бүген көн үткән – шул җиткән.**

**Арба ватылган – утын,**

**Үгезе үлгән икән- ит.**

**Эшләгәннән кем баеган?**

**Иркенләп бәйрәм ит,**

**Дөньяга елый-елый кил дә**

**Уйнап-көлеп кенә яшәп,**

**Җырлый-җырлый гына кит.**

**Бу да бүгенгеләр девизы.**

**Күпләрнең яши белмәве –**

**Замана чире,замана тормозы.**





## Директор апа

### хикәя

**Лилия Хәбибовна атнасына бер тапкыр, вакыт тапканда,башкара торган шөгыле – газета актаруны районкадан башлады. Анда- санда вакытлы матбугат битләрен караштыра ул. Күзе төшкән , күңеленә хуш килгән нәрсә очраса, күп укыганлыгын күрсәтер өчен, ай буена икенче нәрсә укыганчы, шуны теленнән төшерми. Дөрес, шигырь, хикәя,парча кебек әдәби жанрлар язылган бит аны кызыксындырмый, белдерү- рекламаларга да исе китеп бармый. Күз йөгертүне район гәзитеннән башлады, әмма әллә ни ерак китә алмады. Бер битне тутырып аның турында, аның мәктәбе турында, аның укучылары турында язганнар. Күзләре, үзе дә сизмәстән , язулар юллары буйлап**

**йөгерде, ләкин нәрсә турында сүз барганлыгын баш мие кабул итмәде.Өстәлдә яткан көзгегә карап, чәчләрен рәтләгәндәй итте, күзлеген бер салды, бер киде. Үртәлсә, шулай эшли ул. Фото сурәтләрне игътибар белән янә күздән кичерде. Исенә төште: Уфага экскурсиягә баргач,укучылар белән төшкән фотолар бит бу. Балалар үзләре төшергән иде, ләбасә. Менә монысы ботаника бакчасында, монысы лимонариядә, монысы циркта. Компьютер нәрсәләр генә эшләми, укучылары да уйлап чыгара белә: директор филнең борынына ук менеп утырган, әйтерсең, үзен бастырып йөргән Кинг Конгтан качып сыеныр урын тапкан. Ул цирк белән үзе бер мәрәкә булды: балаларның акчасы юк,күрәселәре килә. Шунда телләренә шайтан тартып китергәндер инде, детдом дигән сүзне.**

**-Ятим балалар, карасыннар инде, күңелләре булыр, басып булса да торырлар, гомергә сезгә рәхмәт укырлар. Башкача алар үз гомерләрендә, бәлки,Һиндстаннан килгән филләрне беркайчан да күрмәсләр,- дия- дия ялына-ялына буыннарына төшеп,адинистраторга акча төрткәч, максатларына ирештеләр, мөкиббән китеп, цирк карадылар. Аңа инде биш былтыр. Чәчен дә юньләтләп җыя белмәгән татарт теле укытучысы әллә шаярып, әллә чынлап (аңламассың анықын):**

**-Лилия Хәбибовна, сюрприз – беренче апрельгә Сезне артыгызга утыртырлык прикол эшлим дигән иде, юлъяма язган икән.**

**Мәкаләне хәзер (фотоларны карап, хәтер тартмасын актаргач,) йомшак кәнәфигә утырып сыман ,яңадан**

**укып чыкты. Аклы- күкле булды. Тереләй суйган бит, кеше күзенә ничек күренерсең, ышандыра белә филолог. Директорның чип-чи ялган дигәненә ышанырлармы икән ? Булмас, белмим.**

**Күзләр үзеннән үзе көзгегә йөгерде. Кинәт ун елга картаюын тойды. Буялган чәч тә өстәге киемнән әллә ни аерымый гына йөзгә картлык кыяфәте өсти , алкалар колактагы тишекне зурайтып асылынып төшкәннәр, ирене буяган иннек кан ялаган этне хәтерләтә. Башка чакта бер-бере өч меңнән артык түләп куйдырган тешләренә сокланып, шул ук вакытта горурлык белән карый иде. Бу юлы алар да каефне күтәрмәде, киресенчә, авызың рәтләп ябылып бетми, алтмышка җитәсең, пенсиягә кит дигән карашка теләктәшлек иткәндәй булдылар.**

**Үзе дә юләрнең юләре инде.**

**o Ни диеп кенә минем турыда гәзиткә язмыйсың, тегене дә язасың, моны да язасың, - дип эче пошкан саен, теле кычыткан саен, пумала башның колак итен, җае чыккан саен, ярыйсы гына кимерде.**

**Ярар, кимерсен дә ди, редактор үз кеше, кисәтергә булмыймени, рәхмәт инде , кеше арасында ай саен ук булмаса да ике айга бер Лилия Хәбибовнаның җитәкләгән мәктәбе, я ире, я балалары турында мактау мәкаләләре бастырып тора. Әле бу хәбәрне авыл хәбәрчесеннән алу белән, олы башын кече итеп, мөхәррир шылтыраткан иде. Кая ул аны эндәштереп тору:**

**-Беләм, мин хәбәрдар, берүк-берүк бастырыгыз, язарга үзем куштым, буш итмәбез, коры кашык авыз ерта, безнең яклардан үткәндә чәй эчәргә сугылып чыгыгыз, рәхәтләнеп иркенләп сөйләшеп утырырбыз,- дип, күп белгәнен белдереп, сүзен бетерде. Телен корт чаккыры, әзрәк сабыр итеп, - нәрсә турында яза, минем укытучым? - дип сорыйсы калган. Юләрне чәчеп үстермиләр. Терсәк якын, ләкин тешләп булмый. Пычаксыз суйдылар. Киләсе елга ничек үч алырга белер. Белеп торсын, унсигез сәгать дәрес күрәсе башы юк, кабинет диеп тә авыз ачмасын, классы да булмаячак шул көнҗәлә башның. Икенчесендә кем җырын җырларга өйрәтербез.**

**Башка газеталарны караштырыга күңеле ятмады. Мәңге булмаганны үзе дә сизмәстән мәкаләне яңадан укырга керешге.**

**Бүздәклеләрнең Һиндстанга сәяхәте.**

**Минем дусларым күп. Күптәнге таныш шалтырата:**

**-Алло. Хәлләр ничек? Отставкага китәм. Частьне тараттылар. Миңа вертолет һәм күктәге хәл - вакыйгаларны визуально күзәтә торган индикаторлы - калай белән тышланган тимер будка эләкте. Будкасын гараж хакына сатып җибәрдем. Шәп булды. Вертолетны сиңа илтәм.**

**-Кирәкми, берүк китерә күрмә. Миңа нәрсәгә ул? Мин оча белмим. Оча белсәм, такси урынына файдаланырга булыр иде, алай документы да булгач.**

**-Очмасаң, теләсә ни эшләт. Бала-чаганы чакырып сүттер дә металлын төслесен төслегә, карасын карага аерттыр. Урамыгыздагы тимер җыючы Заһир хәзер самопалга алмаштырып китәр.Берәр кирәгеңә тотарсың, файдасы чыккан саен, миңа рәхмәт укырсың.Монда кайда куям мин аны?**

**-Кирәкми, кирәкле нәрсә булса, синең белән миңа бирмәсләр иде. Нинди юкка чыккан чүп бар...**

**-Сөйләп тә торма. Ихатаңа китереп куям. Чебеш ябарга булса да ярар,-диюгә, акчасы беттеме, тел боткасы пешерүне кирәк тапмадымы,телефон сүнде.**

**Үзсүзле кеше инде ул, малай, китерер. Ихатада вертолет сыярлык түгел, борылырлык та урын юк. Ике малайның ике машинасы ике урында көрткә күмелеп утыра. Ирнең колхозны бүлгәләгәндә тигән тележкасы (арбасы) белән йөрмәгән Т-40 белорусы тутыгып ята. Җыен үтмәс товар бездә, җитмәсә, кышкылыкка карый алмыйм, - дип зур әти атын китергән иде. Шуның чанасы үтсәң- сүтсәң комачаулап тора, ихатага шул вертолет кына кирәк, шул гына җитми. Аңлатып кара син аңа. Капка төбенә куйдырыр идең, авыл советының рөхсәте юк.**

**Уйладым-уйладым да мәктәп директорына киттем. Анда мәктәпнең хан заманыннан калган гараж кебегерәк нәрсәсе бар (гараж булганчы, совет чорында котельный хезмәтен башкарган бина)**

**Чирек азагы, каникул алды көннәре директорның эше күп чак. ЕГ (БД-бердәм дәүләт имтиханнарына**

**укучылар исемлеге кирәк дип югарыдан башын катыралар,төрле конкурсларда катнашырга боерып, кочагы белән электрон почта килгән. Без (кул астындагылар) кайсыбыз аттестация үтә, әле печәт, әле култамга, әле тегене-моны сорап җанына тиябез. Кемгә ял, кемгә грант кирәк. Аның кырыкка ярылырга торган чагы. Ул кызык характерлы кеше безнең, уйларга урын калдырмый: бер генә әйтә. Аныкы я – ярар, я – юк. Мине тыңлап торганнан соң:**

**-Кайчан? - ди ук кебек казала торган күзләре белән күзгә карап. Ул, кешенең күзенә карамыйча, сөйләшә белми.**

**-Бүген, иртәгә инде, - дим аяк бармакларымнан күземне алмыйча. Сүз бетте. Ул бүген уң аягы белән торган. Аның каршы түгеллеген гараж алдының көрттән ерылып, ялтырап ятуыннан белдем һәм тынычлап иркен сулап кайтып ашарга утырдым. Тәрәзә каршысында каз- кошны куркытып, вертолет пропеллирын җилпергә тотынды. Әйтеп торам, ишегалдында борын тыгарлык урын юк. Аңа ышансаң, я каридор башына төшәр. Мобильникка үрелдем:**

**-Шунда, шунда бар, хәзер барып җитәм,- дим.**

**Барсам, танышның авызы колакта, директор да елмая. Улмы соң инде мәктәп территориясенә килеп кергән кешене файдаланмыйча кала, мәктәп файдасына эш эшләтмичә кулыннан ычкындыра торган кеше.Кай арада минем таныш аныкына әйләнгән, кайчан дуслашып өлгергән, миңа сүз әйтергә дә җай юк, теле**

**телгә йокмый, бер алдына, бер артына төшә, май урлап ашаган мәче диярсең. Директор апаның үзенең наполеонский планнары бар икән. Миңа мөрәҗәгать итеп:**

**-Сез бу иптәш белән армиядә бергә хезмәт иткәнсез икән, килешү төзеп, океаннарда корабларда йөзгәнсез, чит илләрдә булгансыз. Китте тезеп (мин белмәгәннәрне белә), колагың гына чыдасын. Как рас каникул башланды. Җыегыз балаларны. Һиндстанга экскурциягә барыйк, укучыләрның да күңелләре булыр. Сезгә дә газетага язарга материал булыр. Кеше арасында бер ял итеп кайтырбыз. Өзми дә куя.**

**Каникулга киткәндә генә, укучыларга тегендә-монда чыгып йөрмәгез, укуыгызны укыгыз, имтиханнарга әзерләнегез, карга боткасына ике аягыгызның берсен атлыйсы булмагыз, ишетсен колагыгыз дигән кешенең көн эчендә фикере йөз сиксән градуска борылды.**

**-Хәзер вертолетлар бензинга эшләми, газга гына оча, -дип аңлатырга тырышып карыйм. Юк, үз туксаны туксан. Телфоннан бер SMSка җибәргән иде, ире эшләгән җирдән ун газ балоны китереп җиткерделәр. Сүзе үтә.**

**Бала-чага кызык бит, аю биетәләрмени, вертолет карарга җыелдылар.**

**-Бу кадәре кеше вертолетка сыямыни? - дип сораганны ишетми дә. Үзенекен эшли инде ул, кулыннан килмәгәнгә пенсиядәге адәмне директор итеп тоталармыни? Буш урыннарга кабинетлардан**

**бәләкәйрәк урындыклар чыгартты. Хәвефсезлек кагыйдәләре бозылуга да күзләрен йомды, күрмәмешкә салынды. Куйган максатына ирешми туктамый ул.**

**-Берни булмас, курыккан эш хәвефле була, аллага тапшырыйк, -дип, үрнәк күрсәтүче коммунист сымак, урын калмаудан куркып, иң тәүгеләрдән үзе кереп утырды. Балаларны урнаштырып беткәч, вертолетыбыз өскә таба курс алды. Кысыгырак инде кысыклыкка, бер кичкә кер мичкә дигәндәй, аның каравы Һиндстанны күрәбез. Чыннанда яшь чакта анда берничә тапкыр булган бар. Сагындырган икән, яңадан күрәсе килә башлады.**

**Күккә күтәрелеп киттек. Әллә ни бик биек тә менмәдек, шәһәрләрнең завод торбаларына тияр-тимәс кенә очабыз. Бөтенесе безгә бармак белән төртеп күрсәтәләр. Кытай территориясе өстеннән узганда, тәрәзәдән кул болгыйбыз. Безне ил башлыгы күреп калган да телеграмма суккан: "Бүздәкләргә кытайский зур сәлам! Сезнең белән горурлана бар галәм".**

**Директорның ,монда туктап, ил башлыгы белән акыл сатарга, хәл алырга бик исәбе бар иде. Тыңлата алмады вертолет идарәчесен. Син әйткәнне тыңларга ул синең ирең дә, укытучыларың да, укучыларың да түгел шул. Аның үзенең законнары: кайда туктарга, кайда туктамаска белә. Төшеп кара син Кытайга: хатын кыз чүпрәк , я очсызлы товар күрсә, доньясын оныта, каникул беткәнче дә кайта алмассың.**



**Һинд вакыты белән 12 сәгать 96 минут. Һиндстанның башкаласы Делига килеп төштек. Затлы машиналарга утыртып, президент йортына алып киттеләр. Әйткәнемчә, миңа бу ил яшь чактан таныш. Индира Ганди заманында өч тапкыр биредәге портта туктап тоганым бар. Һиндстан электән бик бай ил. Океныннан тоткан балык эченнән кызыл һәм кара икраларын алып банкаларга бикли, өстәл киңлек балыкларын аерым рецеп белән тозлап ыслый торган идек. Монда яшәүчеләрнең һәркайсының катлы-катлы үз йорты чәчәкләргә күмелеп утыра. Бай кибетләр, товарларын тышка ук чыгарып тезеп куйганнар, эчендә сатучылары да юк. Әйберне генә бушка бирмиләр, алырга акчабыз җитәрлек түгел. Күз сатып, үзебезне күрсәтеп, әйберләр карап йөргәндәй иттек. Тарихи комарткыларның исәбе-хисабы юк. Ак йортның каршысында бик матур итеп сыерга һәйкәл куйганнар, халкы сыерга табына. Иң матур кызларны сыерга тиңлиләр, сыер кебек чибәр диләр. Сөтле бикәләр картайса, аны суймыйлар, ихатадан чыгарып кына җибәрәләр. Тау өсләрендә чәй куаклары плантациясе үсеп утыра, анысы акчалы түгел. Күпме кирәк, шул кадәр җыеп ал, иренмә генә. Президент йортының гүзәллеген һәм зурлыгын сүз белән әйтеп аңлатмалы**

**түгел. Анын эчендә адашырлык әллә ике меңләп чутсыз- чамасыз бүлмә бар. Кызганыч, президентның үзен күреп булмады, китап актара икән, борчымадылар. Хәер, күрмәвебез дә яхшы. Без, ашыгып, бүләк мазар да алмаган идек, шул кадәр зур кеше кырына ничек буш кул белән керәсең. Летчик дусыма башкорт балы алган идем, ботала торгач, мәктәптә онытылган. Үзебездә “Могҗизалар кыры” уенына коры кул белән Якубович янына да бару юк. Ашханәләрендә фил сөягеннән ясалган алтын тоткалы пешерү әйберләре, бәллүр савыт-саба, көмеш кашыклар тәкъдим итсәләр дә; исебез китмәгәнгә салышып, Башкортстаныбызда нефтьтән эшләнгән, үзебез белән алып килгән бер генә тапкыр кулланыла торган пласмасс посудаларыбыздан кирәк саен файдаландык; тегеләрне кызыктырып, өйдән алган сало белән икмәкне ашадык. Дөресен генә әйткәндә, болай да юк акчаны әрәм итеп, һинд ризыгы ашап, чирләү куркынычы бар, алла сакласын.**

**Храмнарны, стадионнарны, паркларны, музейларны, чиркәүләрне (мин белгәндә, чиркәүләр юк кебек иде) карап йөрдек. Һәркайсы искитмәле. Үзебезнең мәчетләргә кергән булмаса да, монда килгәч, килешмәс диеп, кереп хәер салып чыктык.**

**Бу илдә эчкечелек, тәртип бозу, парногафия, төнге клуб ише нәрсәләр бардырмы, юктырмы. Белмим, безгә очрамады. Ил мөселман дине өндәгән әхлак законнары белән яши.**

**Бирегә безнең кебек Русиядән килүчеләр күп. Һинд халкы русияннарны “сава ” белә. Фил кырында фотога**

**төшү кеше башына мең сум, чәчкәгә чумып утырган агачлар янында тагы да кыйммәтрәк- якын бармалы түгел. Үзеңнең фотоаппарат, видеокамерадан файдалану катгый тыела, әллә ничә полиция хезмәткәре шуны гына карап тора. Безнең директор укучыларга файда китермәгән көнне йоклый алмый. Шуңа ялганлауга барса барды (изге ялганны коръән дә хуплый икән):**

**-Ятим балалар алып килдек.Аларның атасы-анасы да без, зинһарлар өчен үзебезнең телефон фотоаппараты белән генә булса да бер кадр гына төшик инде. Сез вертолет фонында төшәрсез. Алар Индиягә кайчан киләләр, - дип ялына торгач, яхшы сүз – җан азыгы ди бит, аның йомшак теленә эределәрме, ятимнәрне кызгадылармы, барыбер үз сүзен сүз итте (сез аны фотолардан күрәсез). Каршыгызда ул фотолар. 2009 нчы ел, 1 нче апрель. Үзебезнең вакыт 9 сәгать 30 минут. Мәктәбебез каршысына кайтып төштек.**

**Хөрмәтле газета укучылар!**

**Бүген 1 нче апрель икәнен онытмагыз. Аннан шуны да хәтердән чыгарагыз районкага язылу 2010 нчы ел өчен дәвам итә. Язылыгыз, район хәбәрләре, белдерүләр, котлаулар, рекламалар белән танышырсыз.**

**Хөрмәтле редакция хезмәткәре!**

**Сезгә шуны җиткерәм, директорыбыз Сафина Лилия Хәбибовнаның махсус боерыгы нәтиҗәседә безнең мәктәбебезнең һәр укытучысы, һәр эшчесе, һәр ата-анасы Сезнең газетаны икенче ярты еллыкта да алдырачак һәм яратып укыячак.**

**P.S. Бүздәклеләрнең бу сәяхәте турында язмаган булыр идем. Әлеге-баягы директорыбыз башка мәктәпләр вак-төяк эшләрен дә зууур итеп язып чыгаралар, без әллә ниләр эшлибез, берсен язганыбыз юк,- диеп теңкәмә тиде. Өч көн, өч төн язаргамы, юкмы дип уйладым – уйладым да беткән баш беткән, дип язарга булдым.**

**Директор апа юлъязманы өченегә укып бетерә алмады, кесә телефоныннан таныш музыка уйный башлады. Кәрәзле телефон булгач, җитди сөйләшү булырга тиеш. Теләсә кем белми аның номерын.**

**-Алло. Усманнан бу, Фәзит Фәритович борчый. Сез, Лилия Хәбибовна, мөгез чыгармасагыз, мөгаен, Лилия Хәбибовна булмассыз.**

**-Мин сезне аңламадым бит әле, Фәзит Фәритович? - дип сорау бирде, болай да җыерылган кашларын тагы да җыера төшеп.**

**-Бездән яшереп кенә Һиндстанда булып кайткансыз икән, Лилия Хәбибовна. Лилия Хәбибовна дигән сүзнең һәр иҗегенә, юк һәр хәрефенә аерым басым ясап. Район җитәкчеләре белән килешеп эшләсәгез булмый идемени? Димәк, менә ни өчен урыныннан очкан икән РОО җитәкчесе. Сез елганы башыннан болгатучы. Ботканы пешерә беләсез, үзегез ашамыйсыз гына. Башбаштаклык эшләргә булса Сезне куш..,- дип кыза-кыза тезеп китә башлаган иде, өстәлдәге сөйләшү аппараты телгә килеп аның тавышын басты. Лилия трубканы күтәрүгә, чыбыкның теге башында**

**ревкомиссия рәисенең сөекле тормыш иптәше иң якын әхирәте күгәрчен кебек гөрләргә тотынды.**

**-Бигрәк каты серлесең син, Әйткән булсаң да ияреп китмәс идем. Нигә Һиндстанга барырга җыенуыңны сиздермәдең? Ярый әйтмәсәң дә үпкәләмим. Бүләкләр арасында миңа дип атап алынганы бардыр бит? Нәрсәләр алып кайттың? Әйберләр кыйбатмы? Нигә әле телефоннан тәтелдим. Исән-сау йөреп кайткач әйбәт булган. Иремнең шоферына әйтәм дә хәзер барып җитәм, - дип, сүз әйтергә дә ирек куймыйча трубканы элеп куйды.**

**Лилия чыннанда яңа гына Һиндстаннан кайткан хисне кичерде. Аңа чиксез рәхәт иде. Улмы соң сер бирә торган кеше. Үзе үк , бу ил турында белгәнен дә белмәгәнен дә фантазиясенә кушып, булган сәяхәт турында бик теләп бәян итәргә җыена башлады. Юкка гына директор дигән урынга минем фамилияне кыстырмаган, өйрәтәсе калган күдерәкәйне, өйрәтмәсәң үзләре белеп бер ни эшли алмыйлар, дип үз-үзенә сөйләнеп, көзге алдында күзләрен биетеп алды. Күз ачып йомганчы, үзен бик күпкә яшәреп киткәндәй тойды, йөзендә нурлар уйнады. Чәче дә буяганга һич ошамаган, өстендәге киеме гәүдәсен бик килешле итеп күрсәтә, ходайга шөкер, искитмәле ямьсез юан да, чыбык кебек артык нәзек тә түгел, бөтенесе дә нормада һәм контрольдә. Буяган иннегенә кадәр сиздерми генә яшьлек өсти ,алар арасыннан артистларныкыдай гел елмайган тешләр күренеп тора. Алкалары татар хатын- кызларына гына хас булган тыйнаклык өстиләр сымак. Үз-үзеннән**

**канәгатьләнү хисе аның көч- куәтен аттырып җибәрде, җырлыйсыны һәм биисене китерде. Әйткәндәй, андый осталыкта бар аңарда, кулыннан килмәгән эше юк. Кирәк икән машинасын да йөртә. Юк бераүгә дә бирми әле үз постын, өмет тә итмәсеннәр. Күрсенәр аңарда әле бетмәс-төкәнмәс энергия Һиндстаннан башка илләрне урап кайтырга җитәрлек. Ул чын- чынлап беркатлы баладай Һиндстанда булуына ышанганнан ышана барды. Бөтен эшен ташлап, бик бирелеп, косметикалар тутырылган шкатулкасын актарырга кереште. Тотылмаганнарын читкәрәк алып, куеп әхирәтенә бүләк барлый башлады.**

*******************************

## ШАЙТАН ИКӘНСЕҢ.

**Рәмил ЗИЛдә оча гына. Бер күзе юлда, икенчесе ялтырап торган машина көзгесендә. Ачык тәрәзәдән терсәк яртылаш чыккан. Арттан куып килүче юк. Куе кара калын чәчен җил тузгыта, күрер күзгә чибәр генә егет икән. Маңгайдагы күзлек тә бик килешеп тора,терсәгенә кадәр сызганып куелган шакмаклы күлмәгеме, авызындагы «Казбек» папиросымы, кайсыдыр башка җиреме ниндидер кино артистын хәтерләтә. Герой үзен чын -чынлап кинода уйнагандай хис итә.Әйтерсең, каршысында видиокамера аны фильмга төшерә.Ул юлдан да, чолгап алган мохиттән дә, юл тирәли үсеп утырган тирәк полосаларыннан да, борынны кытыклаган басу исеннән дә, зәп-зәңгәр күктә**

**рәсемдәге кебек катып калган шул ук вакытта ястык мамыгыдай кабарып, камырдай күпереп торган ап-ак болытлардан да, күзләрне чагылдырып кыздырган кояштан да, үзеннән дә бик канәгать. Радиоалгычтан яңгыраган җыр да, күңелгә рәхәтлек биреп, алга дәшә сымак**

**Безне юллар, юллар чакыра,**

**Чакырган юл якын кебек.**

**ЗИЛының канатлары булса, чын-чынлап очар иде. Үзен-үзе белә-белгәннән бирле шофер булу турында хыялланды.Нигәдер укудан ямь тапмады. Мәктәптә аның өчен өч кенә дәрес-дәрес: җыр,немец теле, физика.Калганнары-чүп. Нинди этлек тели, шуны уйлап чыгарып, ат кәмите урынына кызык күрсәтеп, утыздан артык сабакташын көлдереп, укытучыларның җанына тиеп, ләззәт алулар-күптән үткән булса да бүген дә хәтердә саклана. Рус теленнән берәр сүзне дөрес яза белдеме икән,аның каравы,тәрәзә төбеннән чебен тотып алып, канатларын өзеп җибәреп,парта өстеннән узыштырумы; шырпы кабына салып алып килгән тараканнарны, тимерчыбыктан ясаган арбага җигеп җибәреп, дәрестә иптәшләрен шартлаганчы көлдерүләр күптән инде артта калды. Үзе кебек укырга яратмаучылар Рәмилнең авызына гына карап торыр , ул кыйланганны кыйланыр булдылар.Әле дә исендә география укытучысы Әсләм абый тирләп -пешеп яңа дәрес аңлата, картаны су урынына эчә, укучылардан да шуны таләп итә.Күзен йомып, теләсә кайсы шәһәрне, елганы күрсәтә ала. Шәп, күңелгә якын укытучы**

**почмакка бастырып та әллә ни җәфаламый. Гәүдәсен, балачактан арба астында калып, чыккан бөкересе бераз килешсез күрсәтә күрсәтүен. Урындыкка утырган килеш, артына да борылмыйча,җилкәсе аша гына күрсәткеч таяк белән төртеп:**

**-Менә бу Кавказ тавының- иң биек ноктасы..,-дип сөйләмен әйтеп бетерергә ирек бирми, малайның теленнән шайтан тарта. Эчкерсез балалыгы белән үзе дә аңламастан:**

**-Юк, абый, бу Кавказ түгел, Сезнең аркагыздагы бөкере тавы бит, - диюгә, юкны ничек эләктерергә белмәгән әшнәләре партага ятып тәгәри-тәгәри көләргә керешәләр. Бер өзелгән дәресне укытучы яңадан ялгап карасын.**

**Укытучылар да хәйләкәр, Рәмилдән ничек котылырга кирәген беләләр.Беткәнмени мәктәптә кара эш? Я брикет ташырга, я такта бушатырга, я җир казырга, я чүп түгәргә кеше кирәксә, нинди дәрес булуга карамастан :«Сәйфуллин, син барасың»,- диләр дә чыгарып җибәрәләр..Үсмер егеткә шул гына кирәк, сөенә-сөенә ризалаша.**

**Берчак шулай Әсләм абыйлары география укытса да, сыйныф җитәкчесе булгангамы икән, «Киләчәктә кем булырга җыенасың?»дигән темага инша яздырды. Рәмилнең кечкенәдән үк туган иң зур буй җитмәслек хыялы шофер булу. Тәпи киткәч тә самовар кәнфәркәсен руль итеп быжылдап, пипелдәп уйнап йөргән бала беркатлылыгы белән үзенең бөтен**

**планнарын, уйлаган уйларын ап-ак дәфтәр битенә ачты да салды. Могаен, сырлаган иншасында хаталар да күп булгандыр. Укытучы аларны күргәндерме, юкмы (күргәндер, әйтеп торырга вакыты гына булмагандыр, бәлки әйтсә дә онытылгандыр), уктай күзләре белән тишәрдәй итеп текәлеп карап торганнан соң, бугазындагы төеренә, тыгыла-тыгыла, дәфтәрнең полясына кадәр кереп язылган эшне минут эчендә диярлек вакытта вак-вак кисәкләргә өзгәли-өзгәли ерткалап ташлады, төкереген чәчә-чәчә укучысының тетмәсен тетәргә тотынды:**

**-Сәйфуллин, синме- син шофер буласың? Синеме- сине бу укуың, бу тәртибең белән чучка тизәге түгәргә дә аласы башлары юк,-диеп күңеле бушаганчы тезде дә тезде. Тагын нәрсәләр әйтеп бетергәндер,Рәмил хәзер башкаларын исләми. Ә бу сүзләре нигәдер күңелгә кереп бикләнде, метал ашаган тутыктай җанга тынгы бирмичә тик тора.**

**Сигезенче сыйныфны тәмамлагач, имтихан тапшыра алмады Рәмил. Моңа әллә ни пошынмады. Аның кебекләр өчен алда әле күзге сынау бар, анда да булдыра алмаса, белешмә (справка) тоттырып чыгарып җибәрсәләр җибәрерләр, мәктәпләре үзләренә булсын, ике ятып бер төшкә кергән җире юк. Җок җилкә түгел, эшкә урнашыр, беләкләре ныгып килә, гәүдә бар, кулбашлары ярыйсы гына, җитмәсә борын астыннан кап-кара булып,үсмер кызларны үзенә каратып, мыек йоннары беленеп күзгә күренеп калкып килә.Авылда эшче кулларның бик кирәк мәле иде. Бригадир аңа**

**хыялларга бирелергә, тырай тибеп йөрергә ирек бирмәде. Колхозның уңган комбайнерына ярдәмче итеп йөгәнләп куйды. Егеткә иртән торуы кыенрак, шулай да уку түгел инде, юккамыни, борынгылар уку-энә белән кое казу дигән, эш ошады. Монсын илтеп куярга кушсалар- йөгертеп илтеп куя, тегесен алып кил дисәләр- чаптырып алып килә, майларга булса- шунда ук майлап ташлый, сүтәргә кирәксә- момент сүтә,җыяргамы- күз ачып йомганчы өр яңадан җыя. Эшли башлавына ай тулуга, кесә тутырып хезмәт хакы бирделәр. Бу тагы бер башка үстереп җибәрде. Мәктәптән чын мәгънәсендә бизде. Кирәге бар иде укуның, укулары тишекле бер тиен. Кем укып мулла булган, чукып карга булган.**

**Август азакларында тимер-томыр арасында тәмәке төпсәсе суырып, төтене белән уйнап, шөгыль китереп чыгарып, шуңардан тәм табып, кояш бераз күтәрелеп чыкны киптерсен дә арышны сугып ташларга диеп җиенып утырганда, башын калкытып караса, ни күзе белән күрсен, каршында исемен ишетү белән бала йоннарын кабарта торган мәктәп директорын күреп, коелып төшә язды, тәмәкесен артына яшереп өлгерде, кулын пешереп алырга да өлгерде. Директорның усаллыгы каядыр югалган, Рәмилнең кыланмышына игътибарын әрәм итеп маташмады.**

**-Сәйфетдинов, бөтен фәннәреңнән «өчле» куеп аттестатыңны тутырдык. Килеп алырсың, аннан дүрт ягың кыйбыла, ике аягыңның берсен атлап мәктәпкә килеп кеше көлдереп йөрисе булма.Мәктәптә эзең**

**булмасын.- Директор сүзен шулай коры һәм кыска тотты.**

**Бүре дә тук, сарык та исән. Рәмил мәктәптән, мәктәп Рәмилдән исән-сау гына котылды. Авыл рәисе булып эшләп йөргән икетуган абыйсының, энекәше аттестатлы булуын күргәч, башы күккә тиде. Әйтерсең, документны үзе алган, әйтерсең анда «өчле»ләр түгел, ә «бишле»ләр. Аттестат алганның икече көнендә үк, рөхсәт сорап тору нитү юк, районнан юллама юнәтеп, Стәрлетамакның культура агарту уку йортына илтеп тыкты Биредә укуыңның юне булмагач, группаны да укытучыларны да гармон уйнап кына шак катырып, күңелләрен күреп булмый икән. Бөтен талант монда җыелган, ни аның ише генә уйный беләләр. Беренче семестрдан ук, «икеле»ләргә баткан, башы керсә, аягы кермәгән студент кисәгенең көен көйләп тормадылар:**

**-Каян килдең,шунда кит. Юлларыңа ак җәймә,- дип арт ягына тибеп тиз өшкерделәр.**

**Сәйфуллин төшенкелеккә бирелә торганнардан түгел, күңеленә авыр алмады. Сагынуы да хак, кайтты туган үскән авылына. Эчендәген чәчеп сала торган гадәте юк. Өйдәгеләргә уку хәлләре турында ләм-мим. Әнисенең ул кайткан саен тугый торган ятланып беткән бер сүзе бар:**

**-Абзый сүзен тыңлап, шунда укырга бармаган булсаң... Җүнле адәм артист буламы? Ни эше, ни ашы, ни семьясы. Көне-төне өенә кайтып керми, гүләйт итүдән бушамый...**

**Шуны гына көтеп торган Рәмил, үзенә сүз китермәс өчен, кала икмәге ашап, теле ярыйсы гына чарлангангамы, үзе дә сизмәстән, кем белән сөйләшкәнен онытып, дорфа гына:**

**-Каян беләсең?Нәрсә, әллә берәрсе белән гүләйт итеп карадың? Чәмгә тидең инде шул сүзләрең белән. Башка әйтер нәрсәң юктыр. Укуыгызга бармыйм,- дип чыраен да сытмыйча, чарлап куйгандай чатнатып, әнисенең авызын тиз томалады.Каты әйтүен төшенеп алганда, соң иде инде.**

**Әнисе дә ялгышрак ычкындырган сүзен икенчегә борып җибәрмәкче булып, йомшак кына итеп:**

**-Ни булды сиңа, улым, әллә укуың начармы, «2»ләр аласыңмы? Бәлки шәһәр җирендә укытучыларның сорауларын аңлап бетермисеңдер?-дипсорап караган булды.**

**-Киресенчә, әни, сорауларны мин бик яхшы аңлыйм, нигәдер укытучылар минем җавапны аңламый,- дип җаваплады укудан куылган кичәге студент. Терсәк якын, тешләп булмый, ана әйткән сүзләренә үкенде һәм авызына су кабарга мәҗбүр булды.**

**Рәмил авылда калды. Эшне тансыклаган. Нәрсәгә кушсалар, шуңа җигелде, кеше зарландырырлык түгел иде. Икенче көзгә күрше Чакмагыш районына барып, һөнәрчелек училищесының трактористлар курсында укыганнан соң, җиң сызганып, эшкә кереште. Әллә ни озак майтара алмады. Ходай күктән көткәнне җирдән бирде: военкомат шоферлар хәзерли торган алты айлык**

**курска тәгаенләде. Кулга шыгырдап торган өр яңа шофер правасы (таныклыгы) алуга, армия хемәтенә чакырып, повестка тоттырдылар. Менә шунда хыялы тормышка ашты. Ике ел буена ике кулыңа бер руль. Бер эләктергәч, ычкындырулар кая. Башта йөк ташу машинасында хезмәт итте, соңнан остаргач, командирын йөртте. Армиядән соң вооенкоматка исәпкә(учетка) баскан көнне үк район үзәгенә шофер булып урнашты. Эшен үлеп ярата Рәмил. Машинасының һәр тын алышын, йөрәк тибешен тоя, кызларны иркәләгәндәй, сыйпап-сөеп кенә тота, юып-майлап кына асрый, көзгеләрен һәр даим алтын балдакны ялтыраткан сыман ялт иттереп кадерләп кенә йөртә. Эшендә начар гадәтләре булмаган, спиртлы эчемлекләр белән мавыкмаган бу яшь егетнең абруе зур,аны да хөрмәт итәләр, яраталар. Гел яңа машинага күчереп торалар.**

**ЗИЛ тизлеген кәметә төшеп әкеренәйде. Шофер күзенә маңгаендагы күзлеген төшереп киде. Юл чатындагы тукталышта укыган чактан ук таныш уңып беткән куе яшькелт төстәге пинжәктән бөкересе тырпаеп торган, гомер буе киеп яньчелеп беткән соры эшләпәле сыйныф җитәкчесе басып тора. Бер кулында иске лавсан итәктән тегелгән шактый гына тузган сетка-капчыктан сөтле башы ерактан ук күзгә ташланып торган литр ярымлы шешә, икенчесен машина туктатырга күтәргән. Рәмил болай да туктыйм-туктыйм дип килгән машинасының тормозларына басып шып туктатты.**

**-Бүздәккә кадәр утыртып алып бармассыз микән?**

**-Утырыгыз, утыр. Кемгә, нәрсәгә барасыз? Нинди җилләр ташлады?Ни эш бетереп йөрисез?-дип, очраган бер кешегә бирә торган дежур сораулар белән күмеп ташлады шофер.**

**Пассажир сөйләшергә сусаган идеме , кызыксынучыга иренмичә,җайлап кына һәр сорауга сабыр гына метекләп, дикъкать белән җавап кайтарды. Үз чиратында ялгыз гына сөйләнеп баруның тәме беттеме, сүз чишмәсе саектымы, шоферны да әңгәмәгә катнаштырасы килепме, сүз ияртә сүз чыксын дипме, юлдан күзен алмыйча тыйнак кына сорап куйды:**

**-Син үзең кайсы авылдан буласың,балам?**

**-Мин бу якныкы түгел, абзый. Читтән килдем. Сезнең Бүздәк якларыннан Рәмил Сәйфуллин дигән егет белән армиядә хезмәт иткән идек. Хәтерләргә тырышып карыйм, кайсы авылдан икәнен-тик искә төшми, күрешеп чыгарга исәп бар, һич югы сәлам тапшырырга иде.Шуны гына көткән кебек, пассажир җанланды, сүзне эләктереп тә алды,әйтми калмыйм тагы дигәндәй:**

**-Безнең Түрештән бит служагың. Менә монавы төшемдә утыра ул,-дип тамак төбенә төртеп күрсәтте. -Тереләй гүргә генә тыкмады. Укыган чагында кыйланмаганы калмады. Артыннан әз йөртмәде ул мин картлачны. Дәрестән качу дисеңме, ачы яздан дәрескә кермичә, мәктәп ихатасында туп тибү дисеңме... Эт малай иде. Ике бармагына резинкә тагып, рогатка ясап кәгазь-чүп, ручкасын нәзек торба итеп, пуф-пуф килеп авызы белән я борчак, я шомырт атып утыру дисеңме.**

**Әрләгәнгә селкенеп кенә дә карамый, үз туксаны туксан, тел озайтырга күп сорамый. Теленә шайтан төкергән нәрсә. Үзең гаепле булып каласың, лутче эндәшмәгәнең. Математика укытучысы нәрсә була инде ул синус белән косинус дигән сорау биргән икән. Рәмил кул да күтәрми, утырган урыннан:**

**-Минем әти,-дип әйтә ди,-безнең сүзләр түгел алар, улым. Русча печән дигән сүздән алынган. Синус- әле чабылмаган печән,ә косинус- чабып, күбәгә өелгән печән.Әтиләрне шулай дип өйрәткәннәр. Әле дә шулайдыр инде.**

**Дәрестә теленә килгән бер кирәкмәгән, теләсә нәрсә сөйләп, тартай теленнән таба дигән шикелле, укытучыларны үзенә каршы котыртып тик утыра. Иртәгә контроль эш икәнен әйтеп җибәрсәң, ник әйткәнеңә үкенеп бетә алмыйсың. Икенче көнне һич тактага язып булмый. Иртән иртүк килеп, сыйныф тактасын шәм белән ышкып куя икән чукынык малай. Мәктәптә нинди шуклык булса, безнең класс уйлап чыгарган.Кемнең этлеге дисәң, шул Сәйфуллинныкы. Каян башына килә, җитмәсә,башкаларны да үз кураена биетә, чукынчык. Чукынчык сүзен утырып баручы аерым интонация белән әйтте . Ул укучысын сагындымы, мәктәптә яшьлеге үткән гомер юлларын искә төшердеме? Аңлавы кыен иде. Хатирәләргә байкау ясап килә торгач, юлның озынлыгы сизелмәгән, бер саплам җеп кебек кенә тоелды. Кирәкле урынга килеп җиткәннәрен сизми дә калганнар.**

**-Шушында туктатырсың инде, улым. Сәламеңне әйтермен. Ничә тәңкә бирәем?**

**-Бер тиен дә кирәкми, абый. Сезнең җаныгызны ашаган Сәйфуллин мин булам бит,- дип җаваплады егет, мыек астыннан елмаеп. Элеке укытучы, сөйләп эчен бушатканга, әз генә дә үкенми, югалып та калмый, шоферга күзлеген салырга кушты. Аннан соң энә кебек кадап карый торган күзләре белән Рәмилнең кызарган йөзенә туп-туры карап, ихлас көлеп җибәреп:**

**-Шайтан икәнсең син Сәйфуллин,-дип кабина ишеген ача башлады.**

**……………………………………………………………………..**



# ЯЗМЫШ  КИРТӘЛӘРЕ

**Талибә булгач, Нуриянең әнисе белән серләре элекегә караганда да ныгырак беректе.Үзе дә сагынып кайта, өйдәгеләр дә ял көне җиткәнне дүрт күз белән үлә язып көтеп алалар.Таба чыжлаталар, тәм-том пешерәләр. Нурия ишектән кайтып керүгә, өйгә үзенчәлекле ямь өстәлә, кот куна. Өстәлгә чәй тәме — шәһәр күчтәнәче куйгач, сеңлекәшләренә вак-төяк бүләк биргәч, өй эче тагы да нурланып киткәндәй була. Умарта кортлары сыман гөжләшә-гөжләшә озак итеп, табын артында утыралар. Әллә ничә ел күрешмәгән кешеләрдәй, чөйкелдәшә-чөйкелдәшә, кысташа-кысташа, әллә ничә чынаяк авылның сөтле чәен бушаткач та туган як хәбәрләрен, шәһәр яңалыкларын кабат -кабат сөйли-сөйли арып бетәләр.**

**Нуриянең атсыз бармагында кашсыз гына ялтыраган көмеш балдак турында сорашырга теле бик кычтып торса да, әни кеше сабырлыкны эшкә җикте.Болай да кызының кайсы якка булырга белми торган чагы шикелле.Авыл егете Рим белән җиденче сыйныфта укыганнан бирле дус булып йөриләр. Егетнең яше дә, бүгенге көндә эше дә, эше булгач, акчасы да бар. Акыл утырткан.Надежданың башында инде кызым өчен борчыласы юк; Рим әйбәт гаиләдә, күз алдында үскән егет; төскә-башка да сүз әйтерлек түгел, менә дигән; кызларын күтәреп кенә йөртмәсә дә кәм-хур итәрлек түгел; әлеге вакытта никах сәгатьләре генә сукмый торгандыр,- дигәнрәк уйлар уйный иде. Эчтән күңеленнән генә әхирәтенең улын кияү дип кабул итеп**

**өлгергән иде. Нурия, укырга кереп, тулай торакка урнашкач, каршы бүлмәдә яшәгән Илдан белән дуслашып китте.Моның үзенә күрә сәбәпләре бар.Илданнар бүлмәсендә ноутбук эшләп утыра, җитмәсә интернетка тоташтырылган. Студентларга көн саен курс эшләре, рефератлар язарга кушалар. Чит ят җирдә кемгә барып сугыласың, кемгә сүз кушасың - кайда ачык чырай , каршы бүлмәгә инде. Әзрәк укырга кереп, баш-күз алгач, кызларына ноутбук алып бирделәр. Шуның тирәсендә булышып йөргәндә үк, Надежданың күңел күзе кызы Нурия белән Илдан арасында сузылган кешегә күренми торган җепләрне чалымласа да игътибар итмәскә тырышты. Өрлек кебек озын буйлы, киң җилкәле, гел елмаеп кына сөйләшә торган Илдан өметле егеткә охшап тора, күрер күзгә сөйкемле һәм ягымлы. Нуриянең бик исе китмәсә дә егетнең муеныннан гашыйк икәнен җаны булмаганнар гына тоймас.**

**-Әни, без монда барыбыз да бертугандай дусларбыз.Бары- уртак. Булганда бүредәй, булмаганда шүредәй, -дип ихлас көлде кызы.**

**Надежданы квалификация күтәрү өчен Нуриясе укыган калага курслар үтәргә җибәрделәр. Биредә проектлау технологиясенең ивоннацион алымнарын өйрәттеләр. Дәресләрдән соң компьютер артында утырырырга кирәк. Кнопкага басып идарә итә торган нәрсәнең авылдан килгән бичәгә- рәсем укытучысына бирешәсе килми. Я программа бөтенләй югала, я вирус килеп керә, я схеманы төзеп булмый да тик тора.Интернет**

**челтәренә керим дисәң, башкалар булаштырмасын диптер инде, порольләр куеп бетергәннәр.Ярыйсы гына чиләнде курска килгән хатын ноутбук артында, кызын да җәфалап бетерде. Инде дә китереп чыгара алмасалар, Илданга йөгереп керәләр, һич югы кәрәзле телефон аша үзен чакырып алалар.Ул җайлы гына кирәкле кнопкага бер-ике басуга, тыңлаучан ат кебек компьютер баласы эшләнәсе операцияне берсүзсез эшләп ташлый.Ходайның рәхмәте егетнең аңлатуы да күңелгә ятеш, җиңел аңлашыла. Көндә булмаса да кайсы көнне, эштән соң буш вакыты булганда, авылдашлары Рим килеп Нурияне шәһәр белән таныштырга, театрга,паркка, һич югы кичке һава суларга алып чыгып китә.Илдан белән әни кеше икәү генә калалар.Карап торырга ыспай күренсә дә Илдан кыюсыз егет. Юкка гына борынгылар егет булса ут булсын, ут булмаса юк булсын димәгәннәрдер.Үзе кырында утыручыны Надежда кызганып та куя. .Менә ничек биздерәсең аны, компьютерны яхшы белә.Бүгенге көндә компьютерсыз яшәп кара , китаптан гына өйрәнеп булмый, кемнәндер өйрәнергә кирәк..Әле дә ябешкәннәр, утыралар.Ашау да , эчү дә онытылган. Кешене үзенә йота торган әйбер икән бу ноутбук дигәннәре. Үзе уңайлы нәрсә- кайда кирәк, шунда кулланып була.Надежда әзрәк ял итеп алу максатыннанмы, сүз юктан сүз булсын дипме:**

**-Илдан, безнең якта синең исемне ишеткәнем юк.Кем сайлаган инде аны сиңа?**

**-Кем дип,егет кешегә этием инде.Илдан ил даны дигәнне аңлата.Адашлар күп ул минем аылда. Сезнең үзегезнеке дә чын татарныкы түгел ич.**

**-Дөрес әйтәсең, миңа исемне әниемнең энесе куштырган. Мин туган чорда, мәктәпкә рус теле укытырга Надежда Петровна дигән бик чибәр, һәркемне үзенә гашыйк итәрлек укытучы килгән булган. Абыем аны бер күрүдән ошаткан, этиемне миңа шул исем белән атарга күндергән. Әле дә абыем минем өчен Надежда диеп үлеп тора. Бирегә килгәч, юлда көн саен ике кызыкайны күрәм: берсе борынына да, колакларына да алка таккан; икенчесе бөтен битенә юлбарыс кебек итеп сурәт ясаган, танавын түп- түгәрәк итеп карага буяган, песинеке шикелле мыеклар сызып җибәргән. Икесе дә үз-үзләреннән бик риза, и, китеп баралар инде, кем күрсен. Кем күрсен, миннән башка эт күрсенмени,-дип чын күңелдән авыл карчыгыдай елмайды.**

**-Модасы шул бит аларның. Әллә ничә җирдән тиштереп алка киюне персинг, тәнгә тема буенча рәсем төшерүне будиард дип атыйлар,- дип аңлатма бирде,кыюсыз гына көлеп Илдан.**



**Шулай юктан мәзәк табып,гәп корып утырганда, Рим белән Нурия дә кайтты.Кыз башта Римне, аннан Илданны озата чыкты. Надежда, компьютерда өйрәнеп беткәч, кирәге чыкмый башлагач, кызы чүп чыгарып ташлагандай, студентны куып җибәрер микән, дип уйлап куйды.Дуслар булып калсалар бик әйбәт булыр иде. Ләкин Илданның күзе Нуриядән башкага төшмәячәк. Моны Рим сизә, нәрсәдер эшләргә кирәк. Рим эш кешесе гел кызны саклап утыра алмый, аңа да мәктәп бусагасыннан башлап бергә яратышып йөргән Нуриясе генә кирәк.Кызда ниндидер үзгәреш бар шикелле. Ул ничектер моңа кадәр сөеп караган егеткә авылдаш абыйга карагандай карый башламадымы соң. Дөнья хәлен белеп булмый, борын төбе юньләтләп кипмәгән студент кисәге сөйгәненңне куеныңнан тартып алырга күп сорап тормас.**

**Мәхәббәтне сатып алып булмый, ул үзе килә.Нуриясе болай башсыз кыз түгел.Санаулы көн тиз үтә. Бәлки вакыйгаларны ашыктырырга кирәкмидер, калганын вакыт күрсәтер дигән уйларны башына төяп, ун көнлек курсларны тәмамлап, Надежда өйләренә юл тотты.**

**Икесе генә калуны көтеп торган ялга кайткан Нурия, әллә ни озын булмаса да икедән үреп куйган чәч толымын бөтерә -бөтерә, беренче булып, әнисенә серен чиште:**

**-Әни,миңа Рим тәкъдим ясады. Минем алтын яратмаганны белә бит инде. Менә туган көнемне котлап йөзек тә бүләк итте,- дип, алсуланып торган йөзне тагы алсуландырып, бармагындагы балдагын салып, әнисенә кидереп карамакчы булды.**

- **Син нәрсә дип әйттең соң?**
- **Бәйрәм саен көмеш йөзек биреп, барлык бармакларыма да кидереп чык, тик берсе генә буш калсын, ә туй җиткәч, ансына алтынны кидерерсең, яме, - дим. - Көлә. Шул гынамы киртә? Хәзер көн дә бәйрәм китә. Тиздән сигезенче март, аннан паска, беренче май, тугызынчы май, беренче курсны тәмамлыйсың, ди. Киртә шул гына булса, мин үзем синең өчен көненә әллә ничә бәйрәм уйлап табам дигән була.**

**-Шул гынамы киртә? Надеждага бу таныш һәм якын сүзләр. Моннан чирек гасыр элек Бөре шәһәрендә беренче курска укырга керергә баргач, милиционер егет белән таныштылар..Имтиханнарны биреп**

**чыгучыларны кемнедер əти-əнисе, кемнедер туган-тумачасы хəл-əхвəл сорашып каршылыйлар: шатлыкларын бүлешəлəр, кайгыларын уртаклашалар. Чит-ят җирдə башкаларга карап беркадəр кызыгып, беркадəр ятимсерəп торган кызны имтихан тапшырып чыгуына, яңа танышы кочак тутырып чəчəк гөлләмəсе белəн каршы алды. Əллə шуңа бу милиционер егетне яклаучысы, терəге итеп кабул итте, абыйсыдай якын күрде, үзендə ышаныч тойды. Нишлəптер Надяга акыл керсə, дəрт уянмады. Башкалар кебек мəхəббəт утында янмады. Хəрби киемдəге егет җае чыккан саен алып килгəн чəчəклəрдəн вазаның буш торган чагы булмады. Үз дəрəҗəсен, килəсе вакытын белеп кенə килде, имтиханнарга хəзерлəнергə һич комачауламады, киресенчə,тарих, җəмгыять белеме кебек фəннəрне тапшырганда, бөтен билетларга да шпаргалкалар язып бирде; бөтен группа кызларының көтеп алган кешесенə əйлəнде.Кызлар үзлəре дə тыйнак булдылар; китап кортыдай дəреслек кимерделəр; тегендə-монда чыгып йөрмəделəр;ял көннəре җитə башласа, алдан билет юнəтеп,авылларына кайтып əйлəнү ягын карадылар.**

**Өченче курста укып йөргəндə, җаен туры китереп, Николай Надеждадан үзенə тормыш юлдашы булуын үтенеп сорады.Надежда моны көтмəгəн иде, бу хəбəр аңа аяз көнне күк күкерəп, яшен яшьнəгəндəй тəэсир итте, зиһене таралып китте.Лəкин ул үзен тиз кулга алды: һəрвакыттагыча тəкəббер булып кала белде. Əллə ни уш китəрлек чибəрлеге булмаса да сөйкемле сөяге бармы, белмəссең, кайсы ягы белəндер көчле затларны магниттай тарта, егетлəр арасында, бигрəк тə Николай**

**кырында текә кыйлана, бер башка биекрәк тота. Аның кызыл погонындагы калын сары тасманы сыпырып, хәрби исемнәрдә берәр нәрсә аңлаган, югары белемле кешедәй, мыскыллау катыш ясалма тавыш белән, беркадәр гаҗәпләнгән булып:**

**-Укымаган, гап-гади милиционергамы?**

**-Шул гынамы киртә?- дип сораугa сорау белән җавап ишетте. Сержантның күзләрендәге янып торган ышанычлы очкынны күзгә күренеп ниндидер сүрәнлек биләп алды. Ул үзен кирәксез түмәр, алай гына да түгел кисеп ташланган тырнак кебек тойды. Аңарда горурлык бар. Мәхәббәт белән горурлык көрәште. Николай түбәнлеккә төшмәде, үзен үзе кәмсетеп, кабат-кабат килеп кызның теңкәсенә тиеп, күзенә чалынып, абруен төшереп йөрмәде, тулай торакка эзне суытты. Надежда моңардан бернәрсә дә югалтмады да, тапмады да. Тормыш үз агышына ага бирде. Кыз бишенче курсны тәмамлап, дәүләт имтиханнары тапшырып чыгып килгәндә, тиздән диплом алам диеп канатланып йөргән мәлдә, һич уйламаганда, абитурент чактагы сыман, ап-ак розалар гөлләмәсе кочаклаган егет тагын аның каршысына пәйда булды. Үпкәләгәнен сиздермәсә дә, бер ел эчендә өч-дүрт семестр бетереп, читтән торып укып алган кызыл дипломын күрсәтеп:**

**-Имтиханнарны бирүең белән котлыйм. Менә диплом. Хәзер безнең арада киртәләр җимерелгәдер дип уйлыйм. Чык миңа кияүгә.**



**Надежда бу очрашуга әзер түгел иде. Нәрсә дияргә дә белмәде. Таныш тулай торак, өченче каттагы тансыкланган таныш бүлмә.Чәчәкләрен чирекле банкага су салып, тәрәзә төбенә утырттылар. Кояш яктысыннан нурга чумып утырган бүлмәгә тагы да ныгырак ямь кунды, бәйрәм төсе керде. Ачык тәрәзәдән кереп, каян килеп чыккандыр бу биеккә зәңгәрсу күбәләк, ак розалар өстендә канатларын җилпеп-җилпеп торды да, үз итеп килеп тә кунды**

**-Хәзер ризасыңмы? Киртәләр юкмы?**

**-Бар.**

**Надежданың башына килгәнче, авызына килде бу кирәкмәгән сүз. Парад формасы кигән кече лейтенант моны көтмәгән иде, ул баскан урынында катып бөтенләй телсез калды. Кыз фикер туплап, әйтәсе сүзләрен барлап өлгерде, берни булмагандай, исе дә китмичә:**

**-Мин, Николай, Сезне яраткан хәлдә дә Сезгә кияүгә чыкмас идем. Сез, сез бит мари. Менә шул киртә. Нигә шулай түгелмени? Минем акылым мәхәббәтне генә жиңә ала әле. Мин үземә тормыш иптәше итеп бары татар егетен генә сайлаячакмын. Бу беркайчан да бернинди очракта да жимерелми торган киртә.**

**Таштай катып калган телсез егет акырын гына артка чигенде, ишекне шапылдатып ябып, күзненә ак-кара күренмичә чыгып китеп юк булды.**

**Надежда үз үзен бәгърсезлектә гаепләде. Николайның кайсы якка киткәнен карарга уйлап, тәрәзә төбен тутырып утырган, бүлмәгә хуш исләре таралган розалар аша урамга үрелеп карады. Саксызрак кыланып, кайсыдыр төше тиеп киттеме, әллә жиле бәрелдеме, чәчәкле банка өченче каттан очып лапылдап жиргә килеп төшеп челпәрәмә килде. Бүлмә турлап аста шампан шәраплары һәм тартмалы конфетлар тотып диплом юарга дип көтеп торган иптәшләре Николайның алар ягына борылып та карамавын, яшен тизлеге белән алларыннан үтеп киткән егеттән алданрак бер гаепсез чәчәкләрнең жиргә килеп төшкәнен дә күргәч, кызыкай ачуланып чәпәде дип уйладылар, бугай.**

**Надежда, дипломын кулга алу белән, бу яклардан ераграк качарга теләде һәм шулай эшләде дә. Тормыш үз ярлары буйлап жай гына ага бирде. Эше, гаиләсе, тоткан урыны – бар да хатын- кыз бәхете өчен артыгы белән бик житкән. Берүк күз тиеп, кителә генә күрмәсен.**

**Матур гына яшәп ятканда, эш буенча Бөре шәһәренә барырга туры килде. Борынгы кала, укып йөргән яшьлек еллары, студент чакта салган сукмаклар, танауны кытыклап яңгырдан соң бөтен дөньяга тарала торган исерткеч тирәк исләре – бар да сагындырган. Хисләргә бирелеп, йомышларны йомышлап йөргәнче, кояш таулар артына юл тотты. Надежда, төнгә калып, соңгы автобуска чак-чак өлгәште. Соңгы чыгарылыш автобусларының утыргычлары пассажирлар өчен бик йомшак һәм уңай икән. Салонда утлар сүнгән, фараларын кабызган автобус төн дип тормый, тип-тигез итеп түшәлгән асфальт юлдан борынгы мәгрифәтле шәһәрне арта калдырып алга таба жилләрне узып чаба. Яктылык эзләп, тышка очып чыгарга теләп безелдәгән чиркинең тавышына болай да йомылырга торган күзләрне тәмам йокы басты: күз кабакларын күтәреп тә булмый. Утырган килеш йоклап та төш күререп була икән. Укытучы кеше нәрсә күрсен инде. Тавык төшенә тары кергән шикелле, Надя да таныш түгел класста әллә нинди таныш түгел теманы аңлата.Исем өчен бер тыңлаучы юк. Житмәсә, гомер булмаганны, утырган килеш дәреслеккә карап сөйли. Яшәрәм, яшәрәрәбәез дигән фигльне зат һәм заман белән төрләндерүне аңлатакчы. Сүз әйтергә дә ирек бирмичә, урыннан: «Юк, апа, яшәрмисез, картаясыз»- дигән тавышлар**

**ишетелә. Надежда Фәнисовна класста тәрпип урнаштырмакчы, кая ул, гомер булмаганны, укучыларын тыя алмый. Аның каравы югарыдан килгән тикшерүче бик текәлеп, укытучының күзләрен карашы белән бораулый. Хатын бу үзенә, тишәрдәй итеп текәлгән карашны үткәреп җибәрә алмыйча, керфекләрен күтәрде, ирексездән күзләрен ачарга мәҗбүр булды. Йокы аралаш каршында үзенә томырылып карап торган капитанны күргәч, күзләр үзләреннән үзләре, хуҗага буйсынмыйча, башта погонагы йолдызларга, аннан фуражка астындагы зәңгәр күзләргә таба йөгерделәр. Я, ходай, төшме, өнме бу?! Каршысында һич уйламаганда, бөтенләй көтмәгәндә имәндәй нык, төп-төз гәүдәле, күзләренә туп -туры карап торган яшьлек дусы Николайны күргәч, Надя бөтенләй коелып төште. Бу каушау ничек тиз барлыкка килсә, шундый ук тизлек белән юкка да чыкты. Яшь бичә - укытучы бит әле- үзен кулга алып өлгерде. Нигә куркырга тиеш соң әле ул? Җаны урынына утыргандай булды, курыкканын бөтенләй тышка чыгармаска тырышты. Погонында дүрт йолдызчык янган хәрби аны тышка чыгарга кыстады. Бу юлы Надяның чынлап торып коты алынды, йокысы тәмам качты, нигәдер Николай аны урлап алыр да калыр кебек тоелды. Ул автоус урындыгы стенасына бөтен аркасы белән ябышты.**

- **Юк, төшмим, - дип кенә әйтә алды. Капитан да үзсүзле икән.**

- Төшмисең икән автобусны да жибәрмим, - дип хәрбиләрчә өзеп әйтте. Пассажирлар да жанландылар. Башта төрмәдән качучыларны эзлибез дип автобусны туктаткач, шомлаганнар иде, ә хәзер хәвеф- хәтәр юклыгына инангач, утырган транспортларының озак кузгалмый торуына үртәлә дә башладылар. Бөтен кешене үзләренә каратып тору Надяга уңайсыз иде.

- Син машинагызга утыртып урлап алып китмәссеңме соң?

- Юк инде. Ни эшләп мин шундый түбәнлеккә төшим. Бер минутка гына чыгып кер. Автобус кузгалмыйча көтеп торыр.

Надя, салон буйлап атлап килеп, баскычлардан жиргә төште. Көз булгагамы, жил төньяктан искәнгәме, төн салкынча иде. Суык шунда ук тәнгә үтеп керде. Николай, ышык булсын дип, Надяга каршы жилгә арты белән басты. Чалт аяз төнге күктә чекерәнләп балкыган йолдызларга да игътибар итмичә:

- Мин кияүдә, кызлар үстерәм,- диде Надя эндәшми торуның мәгънәсен тапмыйча, тынлыкны бозып.

- Беләм, шул гынамы киртә? Син чакыр гына гаиләмне дә эшемне дә ташлыйм да бөтен киртәләрне жимерәм дә киләм. Яшәгән чагыңда ышыкланыр кешең мин барына ышан.

- Юләр, ышыкланырга , аркаланырга минем ирем бар, балаларымның этисе бар,- дип урынына кереп утырды. Автобус теләр- теләмәс кенә урыныннан кузгалды да кирәкле тизлекне алды. Капитан үзенең

**командасы белән кулын кызыл каймалы фуражкасы читенә тидереп моңсу гына озатып калды.**

- **Әни, нәрсә уйларга бирелдең? Мин бит әле кияүгә чыгам дип әйтмәдем, тәкъдим генә ясады, кулымны гына сорады дидем,- дип иркәләнү катыш, ни сәбәптән икәнен үзе дә белмичә, шырык-шырык көлгән Нуриясенең очынгыч шул ук вакытта үтә ягымлы тавышы аны уятып җибәргәндәй итте, уйларын әллә кая таратты. Ул кызына, аналарча сокланып, якын итеп карады. Яшьләр чибәр була шул, гел көләсе генә килә, ни эшләсә дә килешеп тора. Кай арада үсеп, житеп өлгерде соң әле Нуриясе. Әле яңа гына ак бантиклар тагып, сумкасын көчкә күтәреп беренче сыйныфка укырга кергән иде. Үзе хәтерли микән, өстәл өстендә яткан унлык акчаны күреп аптырап:**

- **Каян килгән безгә бу акча?- дигәч, кызы тагы да ныгырак шак каттырып:**

- **Әни, бишенчедәге үзеңнең классыңдагы аръяк Мәсәй малае Римгә «4»лек булмаса да, «3» куймассың инде ярыймы,- димәсенме.**

- **Бар, кире илтеп бир.**

- **Юк, бу караңгыда курыкмыйча, ничек барыйм, бармыйм,- дип күз яше коярга тотынды Нурия.Ана кешенең сүзе каты булды:**

- **Ничек алдың, шулай илт. Акчаны илтмичә, өйгә кайтып керәсе булма, күземә күренмә,- дип тиргәп чыгарды кызын.**

**Бүген шул Рим кызының кулын сорый. Мәхәббәткә сукмак шул чорда салына башламадымы икән? Нурия дә үткер инде, жавабын да тапкан : ризалашмаган да кире дә какмаган. Кызның һаман әнисенең фикерен беләсе килеп теле кычытып тора:**

- **Әни, нигә бер сүз дә әйтмисең инде?**

**Надяның жавабы әзер түгел иде шикелле. Әзер булса да әйтәсе килмәдеме, сүзне икенчегә борды:**

- **Үтә заманалар, без картаймый, кем картайсын, -дип куйды һәм аналы-кызлы икәүләп, берни булмагандай, жиң сызганып, тавык чүпләсә дә бетәсе булмаган өй эшләренә тотындылар.**

**Язмыш юллары киртә-киртә.**

**Кешемен дигән кеше яши,**

**Шуларны берәмләп китә-китә.**

**Ул телиме, юкмы- барыбер**

**Гомер күренми, сизелми узып китә**

**Ходай сызган яшәеш юлын үтә.**

**Бәхетнең иң олысы – гаилә жылысы.**



## ЧЫРШЫ

### (Мистик хикәя)

**Ләләнең тиңдәшләре сымак Яңа елны бала итәкле, кургашлар тагылган,кабарып торган күлмәк киеп каршылыйсы, өйләрендә матур итеп, чыршы бизәп үткәрәсе килә. Ярар, андый күлмәге булмасын да.Их, менә утлары янып торган чыршы да җитәме соң. Утсызы да ярар иде. Кыйммәт шул чыршылар, урманнан алып кайтсаң, штрафы тагы да кыйммәтрәк. Аның сүзенә колак салучы да , тыңлаган кеше дә юк. Әтисенә көн саен чыршы бәйрәме. Әнисе, чыршы алырлык акчасы булса, могаен, берәр тәмле әйбер алыр, я булмаса газ өчен түләр иде. Юк шул аларның андый**

**акчалары. Әле Кыш бабайның бәйрәмгә биргән күчтәнәчләрен дә:**

**-Кәнфит, печенье ашап, артыгыздан кояш чыкмас,бәйрәмдә ашарсыз.Тәм-том ашаганга, тешләрегез черек. Таң атты исә, теш сызлый дип елыйсыз,-дип әниләре санап кына бирде дә алып, үзе генә белгән урынга яшереп куйды.**

**Шулай да бәйрәм өйдә үз төсен алды. Бергәләп табын әзерләделәр: бәлеш салдылар. Абыйсы баздан бәрәңге мендерде, Ләлә суган әрчеде, әтиләре ит турады, әниләре камыр-комыр белән мәж килде. Борынны кытыклап таралган ис, өйгә генә сыймыча, урамга ук чыгып китте. Әниләре күршеләреннән алып чыгып торган барлы- юклы шикәр комыннан , кешечә яңа ел каршылыйк дип, бал куйган иде, шуңардан көмешкә чыгарды.**

**Кояш баер алдыннан, яраткан бердән-бер сеңлесен үзенчә сөендерү максатыннан, тиз генә чаңгыларын тагып чыгып китеп, Марат зираттан (зират аларга бик ерак түгел) барып матур һәм җыйнак кына чыршы кайтарды. Ләләнең сөенүенең чиге- чамасы булмады.Түбәсе күккә тиде, биеп- җырлап кына йөри. Сагындырган кунакны үзләренчә бик килешле итеп бизәп тә куйдылар: мамыктан кар бөртекләре элделәр; дәфтәр тышының төсле кәгазеннән чылбырлар;ялтырыйклы конфет тышыннан флаглар, йолдызлар эшләделәр. Анын кырына басып, Ләлә әллә кайчан ук бәйрәмгә дип ятлаган шигырын кабат-кабат сөйләп карады: шәп килеп чыга. Кызыкайның**

**сөйләгәнен чыршы төбендәге катыргадан ясаган җәнлекләр (кишер тоткан куян, чикләвекле тиен,озын койрыклы төлке) бик яратып һәм исләре китеп тыңладылар.**

**Бәйрәм, алар теләгәнчә, алар көткәнчә, әйбәт үтте.**

**Кап-кара төн уртасында Ләлә әллә нинди куркыныч төш күреп куркып уянды. Төш дисәң, төш тә түгел, бугай. Өнгә охшаган. Уянды да күзләрен шар ачып катты да калды. Кычкырыр иде, тавышы чыкмый.Баш очындагы ямь- яшел чыршыдан ниндидер бик ямьсез, кап-карадан киенгән,озын кашлы, идәнгә кадәр салынып төшкән сакаллы, акай күзле , шүрәленеке кебек килбәтсез бармаклары белән кызыкайның тузган чәчен сыйпарга теләгәндәй, кыска гына буйлы шөкатьсез карт корбанына кызыккандай, менә-менә өстенә сикерергә әзерләнгән сыман сәер кыяфәт белән этнеке кебек очлы тешләрен ыржайтып аңа карап үзенчә елмаеп тора иде.Ләлә әйтер сүзен әйтә алмады, юрганы астына ныграк яшеренде, диванның төбенә бөтенләй сеңеп бетте. Әмма анда тагы да куркынычрак иде. Нигәдер хәтеренә исән чагында нәнәсе сөйләгән коточкыч хикәятләр кереп оялады. Имеш, кеше үлгәч, аның тырнаклары, сакалы үсә икән. Аларның авылында бер кешене үтерәләр. Күмелеп, күпмедер вакыт үткәч, тишерүчеләр килеп, бу адәмне казытып алып, җинаятьне яңадан тикшермәкче булалар. Мәетне казып алсалар, аның тиресе кибеп бекән ди, ә менә сакал-мыегы, тырнаклакы зур булып үскән, ди, имеш. И курыкты кызыкай, и курыкты.**

**Иртән аның сөйләгәннәрен юньләп тыңлаучы түгел, рәтләп ишетүче дә булмады. Көндез уен белән онытылды. Кич җиткәч, күңеле нидер сизгәндәй, Ләләнең моңа кадәр хуш ис аңкытып торган ,инде танау тәмам өйрәнгән бу чыршы янындагы диванга нигәдер ятасы килмәде. Ни эшлисең, йокларга кирәк. Рәхәтләнеп оеп йокыга китеп кенә барганда, кичәге карт тагы уенчыкка алданган бала сыман, бик бирелеп,аңа текәлеп карап торган кебек тоелды. Менә шәүлә чыршыдан чыкты да, нәрсәдер эзләгәндәй, ашыкмый гына, бер җирне калдырмый,өйне капшап чыкты, үзенә бернинди куркыныч та янамавына тәмам ышангач, җайлап кына шылт иткән тавыш та чыгармыйча, җитез генә, күз иярмәслек тизлек белән кыз яткан диванга сикереп менеп утырды. Калганын Ләлә хәтерләми, ушын югалтты.**

**Икенче көнне , башы авыртып, күңеле боталып, йокыдан уянганда,өй эче шактый яктырган, бозга туңган тонык тәрәзәдән салкын кояш сүрән генә елмайгандай итә иде. Нигәдер көнне үткәрә алмыйча йөдәде. Кич булгач:**

**-Ятмыйм мин ул урынга,ятмыйм,-дип тарткалашкан кызны көйләп торучы булмады. Бәйрәмнән айный алмаган этисе коры гына:**

**-Күп телеңә салынып торма. Каян алыйк сиңа икенче диван? Йоклавыңны бел,- дип авызын тиз япты.**



**Сабыр холыклы әнисенең төнгә каршы өйдә тавыш чыгарасы килми, кызы янына барып ятарга иренең күз карашыннан шикләнеп тора. Шулай да баласын үзе янына утыртып, аркасыннан сөйде дә аның хәтерен калдырмаска тырышып, иркәләгән йомшак тавыш белән:**

**-Ярый, акыллым, абыең карт әтәңнәрдә кунакта бит. Бар, абыең урынына ят,- дигәч, Ләлә ирексездән буйсынырга мәҗбүр булды.**

**Озак кына боргалана-боргалана уйланып ята торгач, йокы үзенекен итте: нәзек озын керфекләр күзләрне каплады. Ниндидер шомлану,көтмәгәндә, уяндырып җибәрде. Күз каршысында мыштым гына карап торган җан иясен, үзенә таба сузылган йонлач кулны, кулда сыер мөгезе кадәр тырнаклар күргәч, ачыргаланып:"Әни!.."- дип кычкырырга теләп, авызын ачты. Сүзе чыкмады, ачылган авыз шул көйгә калды.**

**Бу мизгелдә аңа бәйрәм дә чыршы да кирәкми иде инде.**

